**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитетының мәгариф идарәсе**

# Федераль дәүләт белем стандартлары кысаларында дәрестән тыш эшчәнлек шөгыльләрен модельләштерү

**Казан шәһәре**
**2020**

УДК 372.8
ББК 74.26

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты мәгариф идарәсенең фәнни-методик советы карары белән басылды**

**Рецензентлары:**

**Шәмсетдинова Р.Р.**, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты

**Җамалетдинова З.И.,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты

**Антонова Л.М.**, Совет районы Дәрвишләр бистәсе балалар иҗаты үзәгенең милли белем һәм тәрбия бүлеге мөдире

**Төзүчесе:**

**Зиннәтуллин Р.К.,** Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы

**Компьютерда биткә салучы:**

**Потанина М.А.,** Казан шәһәре мәгариф идарәсенең белем процессын ресурслар белән тәэмин итү бүлекчәсе методисты

**Бачуров В.А.**, инженер - программист

**Федераль дәүләт белем стандартлары кысаларында дәрестән тыш эшчәнлек шөгыльләрен модельләштерү.** Методик җыентык – Казан, Казан шәһәре мәгариф идарәсе, 2020 – 84 б.

Методик җыентыкка дәрестән тыш эшчәнлек буенча үрнәк дәрес сценарийлары, технологик карталар кертелгән. Җыентык гомуми белем оешмаларында эшләүче укытучылар, өстәмә белем бирү педагоглары өчен тәкъдим ителә.

© Управление образования ИКМО г.Казани, 2020

**Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру**
**(гимназия эше тәҗрибәсеннән)**

*Хөснетдинова Эльмира Рөстәм кызы,*
*Казан шәһәре Г.Тукай исемендәге беренче татар гимназиясенең*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Дәрестән тыш эшчәнлек – федераль дәүләт белем стандартының мөһим бер өлеше. Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру ул – тәрбия һәм социальләшүгә юнәлдерелгән барлык эшчәнлек (укыту эшчәнлегеннән кала) төрләре. Дәрестән тыш эшләр гомумдидактик принципларга нигезләнеп оештырыла: максатчанлык, фәннилек, системалылык, эзлеклелек, укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләре, балаларның мөстәкыйльлелеге һәм иҗади активлыгы, тормыш белән бәйлелек саклана. Дәрестән тыш эшләрнең тематикасы, юнәлешләре, төрләре бик күп. Юнәлешләре: рухи-әхлакый юнәлеш; спорт – сәламәтләндерү юнәлеше; эстетик – сәнгать юнәлеше; социаль юнәлеш; гомуминтеллектуаль. Төрләре: экскурсияләр, түгәрәкләр, секцияләр, түгәрәк өстәлләр, конференцияләр, диспутлар, мәктәпнең фәнни оешмалары, олимпиадалар, бәйгеләр, фәнни-эзләнү эшләре һ.б.

Гимназиядә туган телдән дәрестән тыш эшчәнлек рухи – әхлакый, социаль юнәлеш һәм гомуминтеллектуаль юнәлеш буенча оештырыла.

Гомуминтеллектуаль юнәлеш укучыларның проект эшчәнлеген оештыруга нигезләнә. Туган тел өлкәсендәге үзгәрешләрдән соң телгә кызыксыну кимеде. Бу сәгатьләр саны белән генә түгел, ә татар теленең җәмгыятьтә тоткан роле белән дә бәйле. Бүгенге мәктәптә укучыларга инглиз теле укыту күпкә җиңелрәк, чөнки мотивация көчле. Татар теле нигә кирәк? Аннан башка да яшәп була дигән уй белән мәктәпкә килгән кайбер ата-ананы һәм дә баланы икенче фикергә күчерер өчен, татар теле укытучысына бик күп көч түгәргә кирәк. Бу синең туган телең, син аны өйрәнергә тиеш дип, балага телне көчләп тагып булмый, чөнки ул үз ана телен һәр кеше белергә тиешлекне әлегә аңламый. Әнә шул психологик киртәләрне узарга, кайчагында телне өйрәнүгә бик тырышып карышкан балаларны да ничек кызыксындырырга? Татар теле укытучысының эше башка укытучылардан шактый аерыла. Ул хәтта дәрестән тыш эшне дә бик мавыктыргыч итәргә мәҗбүр. Ә телгә кызыксындыру, милли үзаң тәрбияләү ул математика түгел, монда җавап я дөрес, я ялгыш була алмый. Милли рух тәрбияләү айлар, еллар дәвамында дәрестә генә түгел, ә дәрестән тыш чаралар да да, өйдә дә дәвам итә торган өзлексез процесс булганда гына, моңа ирешеп була. Менә шуңа күрә ана теле укытучысы өчен укучыларның проект эшчәнлеген оештыру уңышлы. Бу юнәлештә эшләгәндә, укучы актив рәвештә уйлау, фикерләү, телне тизрәк үзләштерү эшчәнлегенә бөтен гаиләсе белән тартыла.

Гимназиядә дәрестән тыш эшнең проект эшчәнлеге түбәндәгечә башкарыла.

5 нче сыйныфта укучыларны кабул иткәч, аларның мөмкинчелекләре, кызыксынуларын өйрәнеп, эш юнәлеше билгеләнә. Баланы кызыксындыру өчен башта проблемалы сорау куела. Мәсәлән, 10 сыйныф укучысы Гүзәл Зиннәтова кайсы йортта яши? Ул йорт урынында Тукай яшәгән. Шуннан балада кызыксыну уяна. Кайда ул йорт? Тукай анда кайчан яшәгән? Ул йорт нинди булган? Берәр сыйныфта Тукай иҗаты юнәлеше булса, икенчесендә ул – туган якны өйрәнү юнәлеше һ.б. Югары сыйныфларга килеп җиткәндә, укучыда фәнни эш итеп язарлык материал туплана Бер төркем укучы шул нигездә фәнни-гамәли конференцияләрдә катнаша, бер төркеме шул ук конференцияләрдә башка номинацияләрдә чыгыш ясый. Мәсәлән, укучы “Талкыш кәләвә –Яңа бистә ризыгы”, “Яңа бистәдә Тукай эзләре” исемле фәнни эш язып, Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни-тикшеренү конференциясендә катнаша.

Безнең гимназиядә дәрестән тыш эшчәнлектә туган тел буенча түбәндәге проект эшчәнлеге алып барыла.

“Талантлы, син кеше туганым” исемле проект инде дистә еллар буенча популяр. Бу проект укучыга милләтебезнең асыл улларын –кызларын күрсәтү, аларның матур үрнәгендә тәрбияләүне максат итеп куя. Чиреккә бер тапкыр оештырыла торган бу чарага укучылар чирек башыннан ук әзерләнә башлыйлар. Сыйныфның яшь үзенчәлеген истә тотып, укучыларга төрле дәрәҗәдәге эшләр бирелә. Очрашуга киләсе шәхеснең я тормышы, иҗаты, эше, мавыгулары һ.б. өйрәнелә. Бу проект кысаларында гимназия укучылары Т.Миңнуллин, Э.Шәрифуллина, Р.Зәйдулла, яшь шагыйрьләр, Г.Ибраһимов исемендәге институтның тел, әдәбият, сәнгать институты галимнәре, Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчеләре, Татар гаиләсе фонды, милли ризык пешерүче танылган кулинарлар, К. Тинчурин, Г. Камал исемендәге театрлар коллективы белән очрашалар. Бу очрашулар әдәби – музыкаль композиция, түгәрәк өстәл, мастер класс формасында оештырыла. Мәсәлән, беренче чиректә без Театр елына багышлап, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артистлары белән мастер-класс үткәрдек. Укучылар чирек дәвамында театр тарихы белән танышып, иҗади эшләр, спектакльләрдән өзекләр әзерләделәр. Артистлар исә аларның чыгышларын анализладылар, үзләренең киңәшләрен биреп, укучылар белән яңадан өзекләрне уйнап күрсәттеләр. Соңыннан артистлар укучылар белән мастер-класс үткәрделәр. Бу проектның дәвамы икенче чиректә К.Тинчурин театрына укучыларның “Сүнгән йолдызлар” спектаклен карарга барулары, ә 22 декабрь-татар театрының туган көнендә – гимназиянең һәр сыйныфы татар спектаклен сәхнәләштерде. Сәхнә, театр аша укучыда милли үзаң һәм башка эстетик зәвыклар тәрбияләнә.

“Яңа бистә тарихын өйрәнү аша фәнгә кызыксыну уяту” дәрестән тыш эшчәнлек программасын укучылар яратып кабул иттеләр. Аның кысаларында ”Талкыш кәләвә –Яңа бистә ризыгы“ проекты тормышка ашырыла. Бу проект башлануга директорыбыз Шәмсиева Гөлфия Гаязовна сүзләре сәбәп булды. Ул безнең мәктәп укучысы буларак, мәктәп елларын искә төшереп болай дип сөйли: ”Без озын тәнәфестә мәктәп ишегалдында торучы Фәрхия әбигә талкыш кәләвә алырга чаба идек. Бөтен Казан аңа килә иде”. Әнә шул сүзләр безгә этәргеч булдылар. Кем ул Фәрхия әби? Ни өчен бөтен Казан Яңа бистәгә талкыш алырга килә торган булган? Һәм без үзебезгә максат итеп талкыш кәләвә тарихын ачыклауны куйдык. Эзләнү эше ул бер чиректә генә башкарылмый, бу проект озак вакытлы проектларга кертелде. Ел дәвамында без талкыш кәләвәнең татар язучылары иҗатында ни дәрәҗәдә куллануын, аның ничек әзерләнүен, бүгенге көндә дә актив кулланылуын, иң мөһиме мәктәп ишегалдында яшәгән Фәрхия әбинең туганнарын эзләү эше барды.

Укучы дәрестән тыш эшләрдә үзенә дөрес профессия дә сайлый ала, фәнни эшләр язып, ул төрле өлкәләр белән таныша. Мәсәлән, талкыш кәләвәдә пешекче һөнәре белән бергә, ул лингвокультурология, туризм белән дә якыная. Талкыш кәләвә тарихын тикшереп, укучы халкыбыз үткән юлларны өйрәнә, аның көнкүрешен күзәтеп, милләт тарихына хөрмәте арта. Халыкны яшәтә торган чара - тел, гореф- гадәт һәм милли ашлар да. Милли тел һәм мәдәниятне, милләтләр арасындагы тынычлык һәм дуслыкны саклау аеруча мөһим булган безнең көннәрдә әлеге проектны файдалы дип саныйбыз.

Тукайга багышланган проект 2016 нчы елда гимназиягә Тукай исеме бирлү һәм шәһәркүләмендә Яңа бистәне төзекләндерү эшләре башлануга нигез булды. Проект кысаларында һәр сыйныфның Тукай тормышын, иҗатын өйрәнүне максат итеп куйдык. Сораулар, тикшерү алымнары презентацияләр әзерләнде. Югары сыйныфта Тукайның Яңа бистәдәге тормышын тикшерү максаты куелды. Бу уңайдан бистәнең Г.Тукай тормышы белән бәйләнешенә бүгенге көндә игътибар итүчеләр аз. Г.Тукайның тууына 130 еллык чараларда да шагыйрьнең Яңа бистә чоры искә алынмады. Безнең эшнең фәнни яңалыгы да нәкъ менә шунда: кайчандыр шушы Яңа бистәнең бер гаиләсендә үзенә эти-әни җылысы тапкан Тукай эзләрен мәңгеләштерү. Тукайның ике елга якын гомеренең бәхетле елларын Яңа бистәдә үткәрүе һәм шуны тарихка кертү фәнни-тикшеренү эшебезнең актуальлеген билгели. Без тикшеренү барышында Тукайның Яңа бистәдә кайда кайчан һәм кемнәр белән булуын өйрәндек.

Дәрестән тыш эшчәнлекнең бу юнәлеше укучыга Г.Тукай буенча яңа белемнәр генә өстәп калмый, ә үзе яши торган Яңа бистә тарихыннан күпме мәгълүмат бирә, туган якка мәхәббәт тәрбияли. Дәрестән тыш эшчәнлек- дәрес кысаларына бикләнмәгән, әмма шул ук вакытта балаларның белемен дә, зиһе-

нен дә үстерә торган, аларның гамәли шөгыльләренә, зәвыкларына, сәләт мөмкинлекләренә уңай тәэсир иткән тәрбияви юнәлешнең бер алымы. Ул – уку эшчәнлеге кысаларыннан чыккан белем бирү эшчәнлеге, ләкин ул дәрестә алынган белемнәрне киңәйтүгә, тирәнәйтүгә, ныгытуга хезмәт итәргә тиеш.

Дәрестән тыш эшчәнлекнең социаль юнәлешен оештыру кысаларында иҗтимагый эшчәнлекне дә алырга була.Тукайга багышланган проект эшчәнлегендә укучылар әти-әниләр белән бергә Тукайның балачакта тормышка ашмый калган хыялын мәңгеләштерергә уйладылар. Яңа бистәдә яшәгән “Чтапан йорты” урынындагы хәзерге Мәҗит Гафури урамы 3 нче йортка мемориаль такта куеп, Тукай эзләрен яңартырга дигән теләк белән шәһәр мэриясенә дә мөрәҗәгать иттек. Ә нәни Габдулланың хыялын тормышка ашырып, аны агач атка атландырган “Апуш бакчасы” исемле балалар мәйданчыгы төзү теләгебезне мэриядә кире какмадылар, киресенчә, гимназия ишегалдында эшләргә вәгъдә бирделәр. Эшебезнең нәтиҗәсе итеп, “Яңа бистәдә Тукай эзләре“ исемле 20 минутлык видео язма төшердек. Бу видеоязма Тукайның 1891нче елда Казанга килгән Тукайның Печән базарыннан алып Яңа бистәгә кадәр булган маршрутын күзалдында тота. Ә язын Тукай һәм башка татар зыялыларның каберен чистарту – укучыда горурлык хисе тәрбияләргә ярдәм итә.

Дәрестән тыш эшчәнлекнең гомуминтеллектуаль юнәлеше быел Ф.Әмирханга багышлана. Укучыларны кызыксындыру өчен проблемалы сорау куела: Тукайны соңгы юлга озатканда, аны кабергә салганда кайсы хәзрәт булган? Безнең гимназия Зариф хәзрәтнең мәчеттән өенә чыга торган сукмагына аркылы салынган. Кем ул Зариф хәзрәт? Сораулар, эзләнү китә. 7 сыйныф укучылары авторның “Фәтхулла хәзрәт” повестен тикшерәләр, “Ф.Әмирхан –көрәшче” дип атадык бу мини проектны. 1909 нчы елда язылган әсәрендә Әмирхан бер гасырдан соң кулланылышка керәчәк әйберләр турында язган. Укучылар өчен бу гаять кызык эш. Аларны бик мавыктырган смартфонны Әмирхан 1909 нчы елда ук язып калдырган иҷ. Әсәрдән өзек “Кайсы байның хәләл җефетләре икән бу сылу абыстайлар? — дип әйтеп өлгермәде, үзенә якын гына бер җирдә җиңелчә генә звонок тавышы ишетте. Бу тавыш Әхмәтнең куен кесәсеннән килә иде. Әхмәт шул кесәсеннән көзгесымак бернәрсә чыгарды да карап тора башлады. Берәр минут үткәч, Фәтхулла хәзрәтнең артык гаҗәпләнүенә каршы, көзге адәм тавышы белән сөйли башлады. Әхмәт аңар бу нәрсәнең көзге түгел, бәлки көзгеле чыбыксыз телефон икәнлеген сөйләде”. Укучы бу эшләрне бөтен гаиләсе белән кызыксынып башкара, ул Фатих Әмирханның хәзерге заман өчен бик гадәти булган видеоконференцияләрне сурәтләвен дә күрә, хәтта оча торган кешеләрнең дә безнең тормышка киләчәге турында да хыяллана. Укучы интернет челтәреннән тема буенча эзләнүләр алып бара. Татаринформ яңалыклары буенча, экспертлар фикеренчә, 2030 нчы елда “Убер компаниясе очу мөмкинлеге булган

автомобильләр чыгарырга әзерләнә. Шул ук вакытта Kitty Hawk такси урынына электросамолётлар, мини самолетлар чыгаруны күздә тоталар.

Димәк, Әмирхан язган әйберләр барысы да безнең тормышыбызга әкренләп үтеп керә. Оча торган кешеләр турында да язган. Күп кенә чит илләрнең бу эш белән кызыксынулары инде күптән билгеле. Шулай итеп, яңа технологияләр кулланып, Ф.Әмирхан буенча укучы яңа материаллар туплый, бистә тарихын өйрәнә. Әлеге проект эшчәнлегендә Әмирхан образларын рәсемгә төшерү, күргәзмә эшләү, Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан Ф.Әмирхан иҗатын өйрәнгән галимнәр белән очрашып, түгәрәк өстәл үткәрү, язучы иҗатына багышланган фәнни – тикшренү эшебез буенча киңәшләр алып, укучыларның Н.Лобачевский исемендәге фәнни-тикшеренү конференциясендә чыгыш ясау планлаштырылды.

Дәрестән тыш эшләребез системалы эшчәнлеккә нигезләнә. Дәрестән тыш эшчәнлектә дә әнә шулай түбән сыйныфлардан укучыларны тарих, әдәбият белән кызыксындырып килеп, чыгарылыш сыйныф укучысы үз Ватанын һәм туган җирен сөюче; туган һәм рус телен белгән; үз халкын, аның мәдәниятен һәм рухи гадәтләрен хөрмәт иткән; кешелек тормышының, гаиләнең, җәмгыятьнең, күпмилләтле Россия халкының, кешелекнең кыйммәтләрен аңлаган һәм кабул итүче; дөньяны актив һәм кызыксынып өйрәнүче; хезмәтнең, фәннең һәм иҗатның кыйммәтен аңлаучы; укый белүче, тормышта һәм эшчәнлектә белемнең һәм үзбелем үзләштерүнең әһәмиятен аңлаучы; алган белемнәрне гамәлдә кулланучы; социаль яктан актив, законнарны һәм хокук тәртипләрен хөрмәт иткән; үзенең кылган эш-гамәлләрен әхлакый кыйммәтләр белән үлчәгән; гаилә, җәмгыять, Ватан алдында булган бурычларын аңлап кабул итүче; башкаларны хөрмәт итүче, конструктив әңгәмә алып бара алган һәм бер-береңне аңлауга ирешүче; кешегә һәм тирә-юньгә куркынычсыз булган, сәламәт һәм экологик тормыш рәвешенең кагыйдәләрен аңлап башкаручы; һөнәрләр дөньясында ориентлашучы, җәмгыятьнең һәм табигатьнең тотрыклы үсеше өчен кешенең профессиональ эшчәнлегенең әһәмиятен аңлаучы шәхес фәнни эшкә сәләтле шәхесләр тәрбияләүгә ирешәбез.

Ә татар гимназиясенең максаты да милләт өчен киләчәк әзерләү.

## Темасы «Татар орнаменты үрнәкләре. Сөлге»

(«Татар халкы мәдәнияте» дәрестән тыш эшчәнлек программасының 7 нче дәресе)

*Макарова Ирина Александр кызы, Корманова Айсылу Шәүкәт кызы,*
*Казан шәһәре Совет районы «Аерым предметлар тирәнтен*
*өйрәнелә торган 144 нче урта гомуми белем мәктәбе»*
*гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең*
*югары квалификацион категорияле һәм*
*беренче квалификацион категорияле туган тел укытучылары*

**Максат:** Балаларда халкыбызның йола бәйрәмнәренә кызыксыну уяту.

**Бурычлар:**

1. Балаларны милли йолалар белән якыннан таныштыруны дәвам итү.
2. Укучыларның иҗади сәләтен, аң дәрәҗәләрен исәпкә алып, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен, нәфис сүз осталыгын үстерү.
3. Халык авыз иҗаты әсәрләренә кызыксыну уяту, туган телебезгә, халкыбызның йола бәйрәмнәренә хөрмәт хисләре тәрбияләү.

**Дәрестән тыш эшчәнлекнең формасы**: уенлы, җырлы-биюле сәхнәләштерелгән тамаша.

Дәрестә презентация кулланыла.

**Дәрәҗәсе: республика күләмендә ачылу.**

*Укучыларның кайсысы баскан, кайсысы утыра.*

**«Казан сөлгесе»** көе яңгырый.

**Укытучы.** Без бу көйне үткән дәрестә тыңлаган идек, хәтерлисезме?

**1 бала.** Әйе шул, әле генә яңгыраган көй – «Казан сөлгесе» көе. Ул көйне мәшһүр композиторыбыз Салих Сәйдәшев язган. (*1 слайд*)

**2 бала**. Нигә шулай җырларга күчкән соң ул сөлге?

**3 бала.** Сабантуйларында колга башына менгән өчендер, мөгаен. (*2 слайд*)

**4 бала**. Бәлки бу матур сөлгеләр өйләребезне ямьләндереп, бизәп торган өчендер. (*3 слайд*)

**1 бала.** Бәлки шулайдыр да. Һәр борынгы шәһәрнең үз гербы, һәр дәүләтнең баш гербы була. Безнең татар хатын-кызларының да үз гимннары, үз сурәти-гербы бар. Ул – Казан сөлгесе.*(4 слайд)*

**2 бала.** Әйе, сөлгебез халкыбызның күкрәшендә, көндәлек тормышында, җырларында киң урын алган. Хәзер дә шулай: мәйдан булса, җирне алдан күрсәтеп, Сабан туеның колга башларында чиккән сөлге җилферди, бәйгеләрдә иң алдан килгән ат муенына чиккән сөлге салына, туй атларын, туй табыннарын затлы сөлгеләр бизи. (*5,6 слайдлар*)

**3 бала.** Алардагы бизәк-рәсемнәргә халыкның бәхет һәм матурлык турындагы уй-хыяллары, элек-электән килгән гореф-гадәтләре, иң якты хис-тойгылары салынган. (*7 слайд*)

**«Сөлге чигәм» көе ишетелә.**

**4 бала.** Ап-ак якты төстәге тукымадан, төрледән-төрле төстәге кыйммәтле җеп-ләр белән укалы чигелгән сөлгеләрне халкыбыз «Казан сөлгесе» дип атый. Бу сөлгедәге бизәкләрдә ерак болгар бабаларыбыз көнкүрешеннән калган аһәңнәр дә, көндәлек тормыш белән бәйле үзгәрешләр дә чагылыш тапкан. (*8 слайд*)

**1 бала.** Ә сөлгедәге бизәкләр нәрсә турында сөйли?

**2 бала**. Сөлге башларында шактый киң кулланылган сурәтләрнең берсе купшы чәчәк бәйләмен хәтерләтә. Әлеге чәчәк бәйләме бигрәк тә XIX гасыр уртала-рыннан алып, чигү осталарының аеруча яраткан бизәгенә әверелгән. (*9 слайд)*

**3 бала.** Кайчакта бер үк сөлге башында берничә чәчәк бәйләме урнаша. Алар, бер-бер артлы килеп, дулкынсыман бизәлеш тудыралар. Борынгы бабаларыбыз-ның мул сулы елга буйларында яшәгәнлеге әнә шул әнә шул дулкынсыман бизәкләрдә дә ачык күренә. (10 слайд)

**4 бала**. Чигешләрдә тереклек дөньясының асылын чагылдырган сурәтләр дә шактый. Аллы-гөлле күбәләкләр, балыклар, бал кортлары, кошлар чигелгән сөлгеләрдәбез аларның парлы-парлы сурәтләрен күрәбез. Бу парлылык чигү осталарының дөньяны элек-электән бербөтен һәм капма-каршылыклы итеп кабул итүеннән, шулай күзаллавыннан килә. (*11 слайд*)

**1 бала.** Тамбур энәсе белән чигелгән сөлге бизәкләре татар хатын-кызларының сизгер зәвыгын, хыял офыкларын, иҗат тәҗрибәсен һәм осталыгын чагылдыра. (*12 слайд*)

**1 кыз**. Кызлар, әйдәгез бергәләп сөлге чигү серләренә өйрәник әле. («Сөлге чигәм» көе яңгырый. (*Кызлар кулларына чигү алып чигәргә утыралар, сөйләшә-сөйләшә чигү чигәләр). (13 слайд)*

Биюче кызлар чыга, «Сөлге» биюе башкарыла.

**1 малай** *(кызларның чигүләрен карап йөри)*. Карагыз бу гүзәллеккә! Нинди матур чәчәкләр чигәләр.

**2 малай.** Әйе, шуңа күрә аның өчен ир-егетләр Сабан туйларында бил алышалар. Аның өчен малайлар аргамакларда чабышалар.(*14 слайд*)

*«Сабан туе» җыры яңгырый. Колга башына сөлге бәйләп малайлар керә. Икесе билләренә сөлге бәйләп көрәшә. (15 слайд)*

**Бабай.** Рәхмәт, булдырдың. Иң зур бүләк – батырга *(сөлге бәйли).*

**Малай.** Сабан туе, сабан туе –
Иң зур бәйрәм илемдә.
Ак сөлгеләр уйнап тора
Көрәшчеләр билендә.

**1 кыз.** Сөлге – татар кызының уңганлыгына, осталыгына һәйкәл *(сөлгесен күрсәтеп йөри).*

**3 малай.** Кеше тормышындагы бер генә вакыйга да сөлгедән башка узмый. Аның белән янәшә бара.

**2 кыз.** Бала тугач, аны ак сөлге белән төргәннәр *(бала төреп күрсәтә).(16 слайд)*

**4 малай** *(дуга тоткан).* Кыңгыраулар тагылган туй атларын сөлге белән бизәгәннәр. (*17 слайд*)

**3 кыз.** Киленнең каенанасына биргән иң беренче бүләге дә сөлге булган. (*18 слайд)*

*1 малай йөгереп керә. «Туй җыры» көе ишетелә.*

- Туй килә! Туй! Каршылагыз! (*Дугасына сөлге таккан «ат» килеп керә. Каенана белән каената каршы алырга чыгалар.)*

- Хәерең белән, төкле аягың белән рәхим ит, килен!
- Балыннан, маеннан авыз итегез.
- Балдай татлы гомер итегез, майдай йомшак булыгыз!
- Әнкәй, бу сөлге миннән сиңа бүләк булсын.
- Рәхмәт, кызым, сөлгедәй озын, ак, пакъ, матур гомер кичерегез.

**1 бала.** Сөлге - символ. Ул халкыбызның әләме дәрәҗәсенә күтәрелгән символ. Аңарда халкыбызның сафлыгы, чисталыгы чагылыш тапкан.

- Мичтән алган икмәкне ак сөлгегә төргәннәр. (19 *слайд)*
- Кунакларны сөлге өстенә икмәк һәм тоз куеп каршы алганнар. (*20 слайд)*
- Кешене соңгы юлга озату да сөлгедән башка үтмәгән. (*21 слайд*)

**2 бала.** Татар, Казан сөлгесе – татар халкын бөтен халыклар алдында аеру билгесе, әләме.

**3 бала.** Менә шуның өчен дә аны җырларга керткәннәр, шигырьләр язганнар, әдәби әсәрләр иҗат иткәннәр. (*22 слайд*)

Бер укучы **Р.Харисның «Ак сөлге»** шигырен сөйли.

Ихтирамымны белгертим
хак сүз белән:
Кунак килсә, каршыладың
ак йөз белән;
дошман килсә, чыкмадың
кулын юарга,
һәм булмадың ак төстәге
сатлык байрак!
И, ак сөлге, беркайчан да
пычранмадың —

күпме сөрттең гаделләрнең
хәлил канын!
Син көрәштең Сабантуйда,
билгә яттың.
Көрәшченең гаделлеге,
көче артты.
Көрәшләргә озатып калдың
син ирләрне,
сау бул, диеп, кулга кушылып
җилфердәдең,
җилфердәдең кызыл туйлар
пар атында,
әверелеп туйның бәхет канатына...
Җеназада син, ак сөлге,
безнең кулда.
Озатасың гүр иясен
соңгы юлга...
Кичерешләрнең таныш сиңа
һәркайсысы,
илемнең һәрбер шатлыгы,
һәр кайгысы.
Син бит үзең дә халкымның
күңеле төсле —
сөттән сеңгән зур пакьлекнең
бер көзгесе.
һәрбер эшнең, һәр ниятнең
өмете — уңыш.
Кешеләрнең нияте зур,
сөлге, булыш!

**4 бала.** Матур сөлгеләр элдек без
Бәйрәмнәрдә түр якка.
Күзнең явын алырлыгын
Әби чиккән яшь чакта.(*23 слайд*)

**5 бала.** Чүпләмләп чигелгән сөлге –
Әнкәй күңел көзгесе.
Онытылырга тиеш түгел
Өлкән буыннар төсе. (*24 слайд*)

**«Казан сөлгесе»** көе яңгырый. Укучыларның кулларында: кемнең сөлге, кемнең сөлге рәсеме. Алар бер-берсенә күрсәтәләр. Гапләшәләр. Түгәрәккә басалар. Бер-берсенә рәхмәт, комплимент әйтәләр.

## “Халкыбызның күңел җәүһәрләре” дәрестән тыш эшчәнлек программасының 21 нче дәресе

*Фәхриева Лилия Госман кызы,*
*Казан шәһәре Совет районы “108 нче төп гомуми белем мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең*
*I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

| | |
|---|---|
| **Тема** | “Тамчы –шоу” интеллектуаль уены |
| **Формасы** | Түгәрәк |
| **Төре** | Уен эшчәнлеге |
| **Максат** | 1. Укучыларга үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру, сәләтләрен үстерү өчен өстәмә мөмкинлекләр тудыру.<br>2. Төркемнәрдә эшләү, башкаларны тыңлый белү сәләтләрен үстерү.<br>3. Туган телгә, күренекле шәхесләргә карата ихтирам, хөрмәт, горурлык, мәхәббәт хисләре тәрбияләү |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | **Шәхескә кагылышлы:**<br>Иҗади һәм күмәк эшләргә өйрәнү, туган телгә карата ихтирам булдыру.<br>**Метапредмет:**<br>*Танып-белү УУГ:*<br>Логик фикер йөртә белү, нәтиҗә чыгару, гомумиләштерүләр ясый белү.<br>*Коммуникатив УУГ:*<br>Әңгәмәдә катнаша алу, үз фикерләрен әйтә белү.<br>*Регулятив УУГ:*<br>Үз алдыңа максат куя белү; ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру.<br>**Предмет буенча:** укучыларга үз сәләтләрен ачу өчен шартлар тудыру |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, төркемдә, индивидуаль |
| **Җиһазлау** | Китаплар, ноутбук, презентация |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре (УУГ) |
|---|---|---|---|
| **Оештыру Мотив-лаштыру (1-2 мин)** | Уңай психологик халәт яки эш атмосферасы тудыру.<br>1. Хәерле көн, хөрмәтле укытучылар, укучылар! “Тамчы - шоу” уенын баш-лап җибәрәбез. Шат елмаеп бер - беребезгә карыйк, ачык йөзле булыйк. Безнең бүгенге уеныбыз “Халыка-ра туган телләр” көненә багышлана.<br><br>Ике командага бүлү. | Укытучыны сәламлиләр. Ике командага бүленәләр. | **ШКУУГ**: укытучы һәм иптәшләрен хөрмәт итү.<br>**КУУГ**: укытучы һәм сыйныфташ-лар белән эшчән-лекне оештыруда хезмәттәшлек итү.<br>**РУУГ**: эш урынын әзерләү. |
| **Төп өлеш** | **I тур. “Булсаң зирәк, әйт тизрәк”**<br>1.Үлчәүләрдә үлчәнми, Базарларда сатылмый. (*акыл*)<br>2.Кечкенә генә сандыкка бөтен дөнья сыйган. (*китап*)<br>3.Сумка тотып керәләр, белем төяп чыгалар. (*мәктәп*)<br>4.Кайдан башлап укысаң да-Укучының төп эше.<br>Мең дә берне белә, диләр, Аның белән дус ише. (*уку*)<br>5.Өй башына утырган,<br>Җир йөзен нуры белән тутырган. *(кояш)*<br>6. Колга башында йорты,<br>Эчендә аның җырчы. (*сыерчык*) | Төркемнәргә бүленеп эшли-ләр, табыш-макларның җавапларын әйтәләр. | **ШКУУГ**: иҗади һәм күмәк эшләргә өйрәнү, туган телгә ихтирам булдыру<br>**КУУГ**: сорауларга төгәл җавап бирә белү, төркемнәрдә эшли белү, үз фи-керләрен дәлилле итеп җиткерә алу, хезмәттәшлек итү.<br>**РУУГ:** җавапларны бәяли алу. |
| | **II тур. Сорау-җавап**<br>1.Татарларның милли бәйрәме? *(Сабантуй)* | Укучылар сорауларга җавап язалар. | **ШКУУГ**: татар әдәбиятына карата ихтирамлы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2. “И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!” Бу шигырь юлларының авторы кем? (*Г.Тукай “Туган тел*”)<br>3. Мәскәүдә берәү дә юк, Казанда икәү. Ул нәрсә? (*а хәрефе)*<br>4. Агач түгел – яфраклы,<br>Тун түгел – тегелгән. (*китап)*<br>5. Муса Җәлилнең туган елы, көне. (*15 нче февраль, 1906 нчы ел)* | | мөнәсәбәт тәрбияләү<br>**КУУГ**: башкаларны тыңлый белү.<br>**РУУГ**: үзеңнең һәм башкаларның эшен бәяләү. |
| | **III тур. Кем күбрәк мәкаль яза?**<br><br>Бу турда мәкальләрне дәвам итәргә кирәк.<br>**1 нче команда:**<br>Кем эшләми, *(шул ашамый).*<br>Ипи-тоз - *(якты йөз).*<br>Әдәп башы - *(тел)*<br>Татлы тел *(тимер капканы ачар)*<br><br>**2 нче команда:**<br>Ялкаулык –хурлык, ты-рышлык - *(зурлык)*<br>Кунак булсаң, *(тыйнак бул)*<br>Аз сөйлә, *(күп эшлә)*<br>Теле татлының *(дусты күп)* | Мәкальләрнең ахырын язып бетерәләр. | **ШКУУГ**: тапкырлыкка өйрәнү<br>**КУУГ**: үз фикерләрен ачык һәм төгәл итеп җиткерә белү. |
| | **IV тур. “Буталган хәрефләр”.**<br>Бирелгән хәрефләрдән сүзләр төзергә.<br>К, у, ы, у, ч, т, ы –<br>С, д, е, р, ә – | Бирелгән хәрефләрдән сүзләр төзеп язалар. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Ф, ә, т, ә, с, е, н –<br>Й, ы, ф, ы, н, с –<br>Т, п, и, к, а - | | |
| **Ял минуты** | **V тур. ”Игътибарлылык” конкурсы.**<br>Бу турда укучыларга экранда рәсемнәр күрсәтелә.<br>Беренче командага сорау:<br>1. Икенче рәсемдә ничә көчек күрдегез? (6)<br>Икенче командага сорау:<br>2. Өченче рәсемдә ничә каз бәбкәсе күрдегез? (4) | Экрандагы рәсемнәр буенча бирелгән сорауларга җавап бирәләр. | **КУУГ**: сорауларга җавап бирә белү, төркемнәрдә эшли белү, үз фикерләрен дәлилле итеп җиткерә алу, хезмәттәшлек итү. |
| | **VI тур. “ЯҢА СҮЗЛӘР ЯЗУ.” (1 минут )**<br>- Бирелгән сүздәге хәрефләрдән файдаланып, исем сүз төркеменә кергән сүзләр уйлап язарга кирәк.<br><br>**Тукранбаш** | Бирелгән сүздәге хәрефләрдән файдаланып, исем сүз төркеменә кергән сүзләр уйлап язалар. | **ШКУУГ**: төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү<br>**КУУГ**: төркемнәр-дә эшли белү, хез-мәттәшлек итү.<br>**РУУГ:** җаваплар-ны бәяли алу. |
| | **VII тур. “Капитаннар ярышы”.**<br>**1 нче капитан:**<br>1. 21 нче февраль – Халык-ара туган телләр көне. (*әйе*)<br>2. Г.Тукай Кырлай авылында туган. *(юк*)<br>3. Төлке, аю, бүре – кыргый хайваннар. *(әйе)*<br>4. Татар телендә 6 килеш бар. (*әйе*)<br>5. Җылы-салкын сүзләре синонимнар. (*юк*)<br>6. [ө] авазы -нечкә сузык. (*әйе*)<br>7. Җәйнең беренче аенда | Һәр командадан бер укучы сорауларга җавап бирә. | **ШКУУГ**: үз илең, халкың белән горурлану хисләре формалашу<br>**РУУГ:** куелган максатларның үтәлү-үтәлмәвен ачыклау |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | үткәрелә торган хезмәт бәйрәме – Нәүрүз (*юк*).<br>8. Татар алфавитының беренче хәрефе ә. (*юк*)<br>9. Татарстан Республикасының беренче президенты – Минтимер Шәймиев. (*әйе*)<br>10. Атнаның бишенче көне – җомга. (*әйе*)<br><br>**2 нче капитан:**<br>1. Татарстан Республикасының хәзерге президенты – Рөстәм Миңнеханов. (*әйе*)<br>2. “Су анасы”ның авторы – Г.Тукай. *(әйе)*<br>3. Ялгызлык исемнәр кечкенә хәрефтән язылa. (*юк*)<br>4. **[з]** авазы- саңгырау тартык (*юк*)<br>5. Чәкчәк– татар халкының милли ризыгы. (*әйе*)<br>6. Чыгыш килешенең сораулары: кемне? Нәрсәне? (*юк*)<br>7. Атнаның беренче көне – дүшәмбе. *(әйе)*<br>8. Кышын кошлар җылы яктан кайта. (*юк*)<br>9. Сыер, сарык, кәҗә – йорт хайваннары. *(әйе)*<br>10. “Кызыл ромашка” шигырен Муса Җәлил язган. (*әйе*) | | |
| **Йомгаклау өлеше** | - Кадерле укучылар! Безнең телебез – матур, күркәм тел. Әгәр милләтнең теле | Укучылар Э. Мөэминованың “Туган | **ШКУУГ**: туган телгә карата хөрмәт хисе уяну. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кулланылмый башласа, ул юкка чыга. Телен бетердең исә, үз халкыңның әдәбияты да, мәдәнияте дә, гореф-гадәтләре дә бетә. Безнең бурыч – халкыбызда милли аң, милли горурлык уяту, телебезне саклап калу. Тел өчен көрәш – милләт өчен көрәш ул.<br><br>Тел ачылгач әйтә алсаң:<br>“Әни!” -дип,<br>Тел ачылгач әйтә алсаң:<br>“Әти!” – дип,<br>Күзләреңә яшьләр тыгылмас,<br>Туган телең әле бу булмас.<br>Соң минутта әйтә алсаң:<br>“Әни!” – дип,<br>Соң минутта зйтә алсаң:<br>“Әти!” – дип,<br>Күзләреңә яшьләр тыгылыр,<br>Туган телең әнә шул булыр!<br>Э. Мөэминованың “Туган телемә” җыры башкарыла. | телемә” җырын башкаралар. | **КУУГ**:әңгәмәдә катнашу, фикерләрне дәлилле итеп җиткерү. |
| **Рефлексия** | Жюри бәйгенең нәтиҗәләре белән таныштыра.<br>Югары: сорауларга төгәл җавап бирә, сәнгатьле итеп сөйли, актив катнаша.<br>Яхшы: сорауларга җавап бирә, ләкин хаталары да бар.<br>Уртача: биремнәрне үтәргә тырыша, ләкин кыенлыклар кичерә.<br>Бүләкләү. | Үз фикерләрен әйтәләр, үз эшчәнлекләрен бәяли-ләр. | **РУУГ:** җавапларны бәяли белү, үзбәя. |

## Татар халык уен җыры “Кәрия-Зәкәрия”

“Татар халкының җырлы – уенлы иҗаты”
дәрестән тыш эшчәнлек программасының 2 нче дәресе
(1 нче сыйныф, рус төркеме**)**

*Бикмөхәмәтова Ләйлә Зөлфәтовна,*
*Казан шәһәре Идел буе районы «6 нчы гимназия»*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең*
*югары квалификация категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Совет районы мәгариф бүлегенең милли мәсьәләләр буенча методисты*

***Чараның максаты:***

***Белем бирү:*** - өйрәнгән сүзләрне аңлап куллана белү күнекмәләре формалаштыруга шартлар булдыру; татар халкының җырлы – уенлы чарасы белән таныштыру;

***Үстерелешле уку гамәлләре:*** - Укучыларда җырлы - уенлы үрнәкләрен өйрәтеп, аларның интеллект дәрәҗәсен үстерү;

***Тәрбияви:*** - Балаларда тормышка яраклашкан (социальләшкән) шәхес тәрбияләү.

***Планлаштырылган нәтиҗәләр:***

***Шәхси нәтиҗәләр:*** әхлакый-тәрбия кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;

***Метапредмет нәтиҗәләре:***

- ***регулятив УУГ***: ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру; активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
- ***коммуникатив УУГ:*** аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре); парларда һәм күмәк эшли белү;
- ***танып-белү УУГ:*** төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;

***Чара төре***: фронталь эш, төркемнәрдә эш, парларда эш.

***Методлар:*** күргәзмәлелек; телдән сөйләү; телдән контроль; күрсәтмәлелек.

***Предметара бәйләнеш:*** музыка, математика

***Җиһазлау:*** ноутбук; аудиоязмада җыр; тылсымлы таяк; муенга тагу өчен рәсемнәр (әби, бабай, кыз, малай,әти, әни), матур сумка, укучы (рәсем яки курчак); “Бармак” уены өчен минусовка.

### Дәрестән тыш эшчәнлекнең технологик картасы

| Чараның этаплары һәм юнәлешләре | Укытучы эшчәнлеге | Чарага кирәкле материал | УУГ формалаштыру |
|---|---|---|---|
| **Оештыру моменты** | Укучыларны тел мохитенә | - Исәнмесез, балалар!<br>- Исәнмесез, укытучы | **КУУГ:** уку һәм танып-белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| *Максат:* укучыларда психологик рәхәтлек тудыру; укучыларны бер берсенә ихтирам итү хисен тәрбияләү; | чумдыру;<br>Укучылар белән исәнләшү;<br>Укучыларның хәлләрен сорашу;<br>Чараны башлау. | апа!<br>- Сезнең хәлләрегез ничек?<br>- Яхшы, рәхмәт. Ә сезнең хәлләрегез ничек?<br>- Рәхмәт. Минем дә хәлләрем яхшы.<br>- Менә ачкыч, рус телен ябабыз. | процессында позитив мөнәсәбәтләр булдыру, әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; |
| **Актуальләштерү**<br>*Максат:* булган белемнәрне искәртү | Укучыларның игътибарын туплау;<br>Фронталь эш алып бару. | -Укучылар, бу нәрсә?<br>- *Сумка.*<br>- Сумкада нәрсә бар?<br>- *Рәсем.*<br>- Ничә рәсем?<br>- *Бер, ике, өч, дүрт, рәсем.*<br>Рәсемнәр күрсәтелә.<br>- Бу кем?- Бу бабай.<br>- Бу кем? –Бу әби.<br>- Бу кем. – Бу кыз.<br>- Бу кем? - Бу малай. | **Танып-белү**<br>**УУГ:** бирелгән структураларны әйтә белү<br>**РУУГ:** алган белемнәрне истә тотып, уен-күнегүләр башкару<br>**КУУГ**: укытучы һәм сыйнафташларыңны тыңлый белү, дәрестә актив катнашу |
| **Дәрестән тыш чараның мәсьәләсен адымлап чишү**<br>*1) Максат:* чарада яңа мәгълүмат үзләштерергә әзерләнү (рухи - әхлакый юнәлеш) | Проблемалы ситуациядән чыгу юлын күрсәтергә тиеш; | - Әйдәгез, җырлыйбыз. “Бармак” уены. (Башта бабай, әби, кыз, малай дип. Аннан соң укытучы рәсемнәрне буташтырып күрсәтә, балалар рәсемнәр буенча җырлыйлар).<br>- Бабай нинди? – Бабай карт.<br>- Әби нинди? – Әби матур.<br>- Кыз нинди? -Кыз чиста.<br>- Малай нинди?<br>– Малай яхшы.<br>“Әверелеш” уены. | **Танып-белү**<br>**УУГ:** тема кысаларында билгеләрне аерып күрсәтү<br>**РУУГ:** ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;<br>**КУУГ**: парларда һәм күмәк эшли белү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Укытучы тылсымлы таяк белән эшли. Мин –кыз! Мин –яхшы кыз! Мин бик-бик яхшы кыз! Мин –бабай. Мин – карт бабай! Мин бик-бик карт бабай. Мин әби. Мин матур әби! Мин бик-бик матур әби! (Ялгышкан укучы уеннан чыга.).<br>Ә хәзер мин укучы. Утырыгыз, укучылар. Рәхмәт. | |
| *2) Максат:*<br>яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру | Укытучы яңа кунак белән таныштыра, яңа лексик сүзләр кертә. | **Кунак кертү**. Укучы-кунак.<br>Танышу.<br>Исәнләшү. | **Танып-белү УУГ**: предмет һәм күренешләр-не билге һәм символлар белән билгеләү; пред-мет һәм күре-нешләр арасын-дагы логик бәй-ләнешне билге-ләү, аларны бил-ге, жестлар аша күрсәтү. Образга кереп аралашу. |
| *3)Максат:*чараны ң эчтәлеген чишү (эстетик – сәнгать юнәлеше) | Укытучы “синең” тартымы белән таныштыра;<br>Яңа лексик сүзләр кертә.<br>Аудиоязма тыңлау. | -Укучы нинди?<br>-Укучы яхшы, матур, зур, чиста.<br>- Әйдәгез, җыр тың-лыйбыз. (Укытучы рус телендә бу уен турында аңлата.)<br><br>“Кәрия-Зәкәрия”.<br>Бу бик яхшы укучы, бу бик яхшы укучы. | **РУУГ:** нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;<br>**КУУГ**: аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре); |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Аның укуы яхшы.<br>Аннан үрнәк алыгыз.<br>Кәрия –Зәкәрия коммая,<br>Кәрия – Зәкәрия коммая,<br>Кәри кемгә, Зәкәр кемгә<br>Зәкәрия коммая. | |
| *4) Максат:*<br>укучыларга җыр уенлы текстны өйрәтү | Укытучы белән укучылар образларга кереп, жестлар белән җырлы – уенлы текстны өйрәнәләр | Кунак - укучы аудио-язмага кушылып җыр-лый. Хәрәкәтләр бе-лән күрсәтү.<br>Кунак - укучыга ку-шымтада балалар кушылып җырлый.<br>Кунак - укучы һәм балалар җырлыйлар.1, 2 укучы турында җырлыйлар.<br>Алга таба укучы сүзен бабай, әби, кыз, малай сүзләре белән алмаш-тырып җырлыйлар.<br>Уртага чыккан укучы муенга рәсемне элә. Аннан соң образдан чыгара. Рәсемне салып куя. | **КУУГ**: тыңлый белү; диалог төзүдә һәм коллектив белән эшләүдә катнашу<br>**ШУУГ:** күршеңә ярдәм итүдә танып белү инициативасын күрсәтү<br>**РУУГ**: активлык кебек сәләтләрне формалаштыру |
| **Рефлексия**<br>Җыр: “Кәрия - Зәкәрия” | Укытучы җырны кабатлатырга тиеш.<br>Укучылар үз үзләрен бәялиләр. | Җырны бергәләшеп төркемнәрдә башкару. Өстәлләрдә конверт ята. Ул конверт эчендә битлекләр бар: кызыл һәм яшел. Әгәр сезгә җыр ошаса, кызыл битлекне киегез, әгәр ошамаса, яшел битлек. Тактадагы агачка | **РУУГ**: активлык кебек сәләтләрне формалаштыру<br>**ШУУГ**: әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | алмаларны элеп чыгарга кирәк: бугенге чарада яңалык алсагыз, кызыл алма, әгәр яңалык кызык булмаса, яшел алма.<br><br>Вакыт тәмам. Сау булыгыз | |

**Нәтиҗәләрнең дәрәҗәсе**

**1 нче дәрәҗәдә** укучы белемне ала, көндәлек тормышны аңлый.
**2 нче дәрәҗәдә** укучы җырлы – уенлы чараның эчтәлеген тормыш- чынбарлык белән бәйләп уйлана һәм уңай караш тәҗрибәсен ала.
**3 нче дәрәҗәдә** мәктәп укучысы җырлы – уенлы чараны мөстәкыйль рәвештә иҗтимагый эш тәҗрибәсе бәйләп куллана белә.

## “Бәллүр каләм” җыены
## дәрестән тыш эшчәнлек программасының 14 нче дәресе

*Җәләлиева Ләйсән Равил кызы, Макарова Ирина Александр кызы,*
*Казан шәһәре Совет районының «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 144 нче урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең югары квалификация категорияле туган тел укытучылары*

**Темасы: “Онытырга мөмкин түгел”**
**Максат:** Укучыларга Бөек Җиңүгә багышланган шигырьләр, әдәби әсәрләр аша патриотик тәрбия бирү, сугыш чоры кешеләренең җиңүгә булган ышанычын, батырлыгын, рухи ныклыгын аңлату, сәхнәдә образ тудыра алу осталыгын формалаштыру.
**Бурычлар:**
- сценарий үткәрү өчен укучыларга мөмкинлекләр тудыру, гамәли эшчәнлекләрен оештыру;
- укучыларның Бөек Ватан сугышы турыдагы белемнәрен тирәнәйтү;
- укучының аңында әзерләнгән кичәнең картинасын формалаштыру;
- тыңлый белергә һәм башкаларның фикерен ихтирам итәргә өйрәтү, димәк, команда белән эш итәргә өйрәтү;
- уйлап табучанлык сәләтен үстерү;
- гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр :**

***Шәхси нәтиҗәләр:***

– уку эшчәнлегендә үз-үзеңә дөрес бәя бирә алу, үзара дуслык хисен тәрбияләү;
– иптәшеңә рухи ярдәм күрсәтә белү;
– фронтовик язучы – шагыйрьләр, сугыш һәм тыл ветераннарына олы хөрмәт уяту;
– эш барышында укытучы, укучы арасында бер-берсен аңлап төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен булдыру;

***Метапредмет нәтиҗәләр:***

- иҗади фикерләү, мөстәкыйльлек һәм башлап эш итү сәләтен үстерү;
- компьютер белән эшләү, мәгълүматны эзләү һәм эшкәртү күнекмәләрен булдыру;
- куелган максат һәм бурычларга ирешә алу;
- логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйль эшләү мөмкинлеген үстерү.

**Сценарий юнәлеше:** рухи -әхлакый тәрбия бирү юнәлеше.

**Төре:** Проект яклау дәресе (йомгаклау).

**Формасы:** Балаларның сугыш темасына багышлап язылган сценарийларын сәхнәләштерү.

**Дәрәҗәсе:** Мәктәп сәхнәсендә чыгыш ясау, Җиңүгә багышланган район конкурсында чыгыш ясап 1 урын, шәһәр конкурсында 3 урын, республика конференциясендә 3 урыннарны яулау.

**Катнашалар:**

1 нче алып баручы -7 сыйныф укучысы
2 нче алып баручы - 7 сыйныф укучысы
Алсу – укучы кыз бала, 8 яшь
Ләлә – кызның әнисе
Арслан – кызның әтисе
1нче солдат, 2 нче солдат, 3 нче солдат, командир, медсестра – сугышчылар
Хат ташучы
Җир - ана
Ана
Торналар – 3 класс укучылары
Биюче ике солдат һәм ике кыз

**1 нче күренеш.**

*Кыз бала әнисе һәм әтисе белән комлыкта уйный. Бервакыт радиодан Левитан тавышы ишетелә.*
*Әни кеше катып кала. (“Озатып вокзаллар каршыннан” көе яңгырый.)*

**Арслан:** Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.

Менә-балам. Син – әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм:
Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен, туган ил өчен.
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм...

*Әтисе бала белән хатынын кочаклап үбә һәм сугышка китә. Әни кеше кулъяулык биреп, елап озатып кала.*
*Бала әтисе артыннан: “Әтием,”- дип өзгәләнеп кычкыра.*
*Әни кеше:”Арсланым,”- дип елап кала.*

**1 укучы:**

**К.Нәҗми “Фашизмга үлем”**

Завод морҗаларын алсулатып
Аткан чакта сызылып алсу таң,
Көндәгечә тыныч хезмәт белән
Шаулаганда безнең киң Ватан,
Көндәгечә колхоз кырларында
Башланганда шундый кызу эш,
Котырган эт – Гитлер безгә каршы
Сугыш ачты.

**2 укучы:**

Котырган эт –Гитлер безгә каршы
Сугыш ачты, ләкин бу сугыш-
Үз башына булыр ул этнең!
Фашизмга үлем бу сугыш.
*(Сугыш тавышы)*

**2 күренеш.**

*(Блиндаж. 3-4 солдат утыра. Берсенең башын медсестра бинт белән бәйли. Берсенең кулында тимер кружка, су эчә, берсе идәндә сузылып яткан, берсенең кулында рюкзак. Ипи чыгара. Сыйлый.)*

**1 солдат:**

- Эх, күпме дусларыбызны югалттык. Тагын күпме ятим, тол хатын артты дөньяда. *(Ачу белән)* Фашистларга көн булмаячак. *(Йодрыкларын төйнәп).* Һәрбер ятим өчен үч алачакмын!

**2 солдат:**

- Исән калырга насыйп булырмы икән!?

**Арслан**:

- Үлем турында уйлама әле, энекәш! Ничек юрасаң, шулай киләчәк. Ә безне бит өйдә көтәләр. Менә минем өзелеп сөйгән Ләләм, яраткан кызым калды. *(Фото чыгара.)* Үзгәргәндер инде Алсуым минем.

**1 солдат:**

- Ә мин.. сөйгән ярымны югалттым. Ул яшәгән йортка фашистлар снаряд ташлаганнар. Гөлназым минем! Без бит аның белән тормыш кору турында хыялланган идек. Бергәләп бер кыз белән 2 малай үстерербез, бәхетле әти-әниләр булырбыз дип уйлаган идек! Э-э-хх! (*Йодрыкларын йомарлап)* Үч аласым килә! Шул фашист ләгънәтне бу дөньядан юкка чыгарасы иде! *(туктап тора).*

Елыйсы килә... *(үзен кулга алып)*. Елау егет эшемени, эх, бер җырлыйсы килә!

**2 солдат:**

- Сеңлем, әйдә, көйлә әле бер матурны, күңелләребез бушансын, ичмасам.

*(Медсестра "Авыл көен" җырлый, солдатлар уйга чумып тыңлыйлар. 3 нче куплетны бергә җырлыйлар. Җырлап бетергәндә, командир килеп керә. Барысы да торып басалар.)*

**Командир:**

- Сугышчыларым, безгә төн эчендә тел алу бурычы йөкләнде. 10 минуттан кузгалабыз. Әзер булыгыз!

**Солдатлар бергә:**

- Без әзер, командир!

**Җир – ана:**

Ике дөнья бәрелә бүген,
Аяз күктән яшен атылыр.
Ике дөнья бәрелә бүген,
Берсе челпәрәмә ватылыр.

(*Әкрен генә "Таң атканда" көе ишетелә*)

**Арыслан:**

Карт анам,
Мин тудырганга
Үкенмисең... әйеме?
Әйт, анам! Карт анам,
Төнлә йомшак түшәгеңдә,
Матур төшләр күреп ят, анам,
Зинһар өчен...
Мине уйлаганда,
Салкын кичтә мичкә карама,
Мичләр сүнәр: өй карангы калыр,
Лампочкалар яндыр,карт анам,

Синең күңлеңә мин бары тик
Якты буып кына кайталам...

(*Алгы планда Арысланның әнисе пәйдә була)*

**Ана**. Улым, Арысланым минем!
**Арыслан**. Әнкәй... (*кочаклашалар)*
**Ана.** Синме бу, Арыслан улым?
**Арыслан**. Мин, әнкәй...
**Ана**. Улым....
**Арыслан.** Әнкәй!
**Ана**. Чәчләрең нигә агарган улым?
**Арыслан**. Чәч агарыр өчен дә, коелыр өчен инде ул, әнкәй.
**Ана**. Кулыңа ни булды улым?
**Арыслан**. Нишләгән?
**Ана**. Сул кулың күтәрелми түгелме соң?
**Арыслан.** Кайвакытта кулларның күтәрелмәве яхшырак ул,әнкәй.
**Ана.** Күлмәгеңнең якасы ник ертылган?
**Арыслан.** Юктыр ла, әнкәй!
**Ана.** Улым! Бер-ике сүз әйтсәм, акыл өйрәтә дип ачуланма
**Арыслан**. Әнкәй...
**Ана**. Яхшы бул, матур яшә!
**Арыслан**. Рәхмәт, әнкәй.
**Ана.** Илеңне, телеңне, халкыңны онытма. Иманыңнан яза күрмә. Боларны сиңа мин әйтәм, син бүтәннәргә әйт. Бүтәннәр үзләреннән соң килгәннәргә әйтеп калдырсын.
**Арыслан.** Рәхмәт әнкәй (*ана әкрен генә югала*). Әнкәй! ( *Ананың "улым" дигән тавышы ишетелә).*
**Җир-ана.**
Үлгәннәрнең исәннәргә әйтер сүзләре кала.
Исемнәре калганнар һәм исемсез югалганнарның
Әйтер сүзләре кала.
**1 нче солдат:** Без якты дөньяга дәшәбез!
**2 нче солдат**: Йокың сакмы, дөнья?
**1 нче солдат**: Ни уйлыйсың, дөнья?
**2 нче солдат:** Без, дәһшәтле сугышның үтерелгән корбаннары, сезгә-исән кешеләргә дәшәбез!
**Арыслан**: Җирне саклагыз!
**1 нче солдат**: Җирнең бәхете – исәннәр бәхете!
*(Видео күрсәтелә. Сугыш эпизоды. Шартлау тавышы).*

### 3 күренеш.

*(Бүлмә. Әни кеше кызы белән китап укыйлар. Хат ташучы керә).*

**Хат ташучы.** Ләлә ханым, сезгә хат бар.

**Ләлә.** Арсланымнанмы*?(Елмаеп йөгереп килә.)*

**Хат ташучы.** Гафу итегез, сезгә көчле булырга кирәк. Бу кайгы хаты. *(Өчпочмаклы хат чыгара)*

**Ләлә.** *(хатны тиз-тиз ала, ачып укый):* Юк, юк! Бу дөрес түгел*! (Идәнгә тезләнә. Елый. Кызы килеп җиңеннән тарта)*

**Алсу.** Әни, әни! Нигә елыйсың? Тезең авырттымы?

**Ләлә.** Балам, кызым минем! *(Күкрәгенә коча, елаудан туктап кала, торып баса)***.** Алсуым.. Юк, миңа бирешергә һич кенә дә ярамый. Арсланым безнең өчен башын салган бит. Геройларча һәлак булган. Ә мин җебеп төштем. Миңа кызым өчен яшәргә кирәк. *(Әкрен генә сөйли башлый)*

Син яраткан җырларны җырлап,
Күңелемне әзрәк юатам,
Син дә кушылып минем белән
Җырлашасың кебек ерактан.

*("Журавли" көе яңгырый. Алгы пландга бер төркем балалар ак костюм-нардан чыгып, торналар биюен бииләр.*

### 4 күренеш

*(Әни белән кыз чыгалар. Ура кычкыру авазлары. Левитан тавышы)*

**Алсу.** Әнием, бүген нинди бәйрәм? Кешеләр нигә сөенәләр?

**Ләлә.** Җиңү бәйрәме, кызым! Җиңү бәйрәме!

**Алсу.** Ә алар нигә елыйлар соң?

**Ләлә.** Без яшәсен өчен күпме солдатлар һәлак булды! Шуңа елыйлар, кызым. Җиңү көнен якынайту өчен этиең дә яу кырында ятып калды. Ә без, яшибез...! Безгә алар өчен дә яшәргә кирәк, кызым!

*(Вальс бию Ике пар солдат һәм кызлар)*

**1 нче автор:**

- Ветераннар инде бик аз калды.
Кадерләрен белик аларның
Күргәннәрен тыңлап язып алыйк,
Тарихларга кертик даннарын.
Өйләренә барыйк үлгәннәрнең
Толлар хәлен белү саваплы.
Мендәрләрен рәтлик, чәйләр бирик,
Алар өчен без дә җаваплы.

**1 нче автор:**

Сугыштан соң бик күп сулар акты
75 тапкыр килә безгә яз,
75 тапкыр инде май кояшы
Сибә җиргә җылы, бирә наз!
Халкыбызның данлы батырларын,
Горурланып искә алыйк.
Үлгәннәргә башыбызны иик,
Исәннәрнең кадерен белик.

*(Бер минут тынлык. Баш ию.)*

**Тема: “Тамчы шоу ” уены**

**Максат:** укучыларда туган телгә карата ихтирам, мәхәббәт, горурлану хисләре уяту.

**Бурычлар:**

- фикер йөртү өчен укучыларга мөмкинлекләр тудыру, гамәли эшчәнлекләрен оештыру;
- мөстәкыйль рәвештә логик фикерләргә өйрәтү;
- катнашучыларны уенны уздыру турындагы катгый күрсәтмәләр шартларында эш итәргә өйрәтү;
- укучыларның туган тел турыдагы белемнәрен тирәнәйтү;
- тыңлый белергә һәм башкаларның фикерен ихтирам итәргә өйрәтү, димәк, команда белән эш итәргә өйрәтү;
- уйлап табучанлык сәләтен үстерү;
- халык авыз иҗатына карата хөрмәт хисләре тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

*Шәхси нәтиҗәләр:*

- уку эшчәнлегендә үз-үзеңә дөрес бәя бирә алу, үзара дуслык хисен тәрбияләү;
- иптәшеңә рухи ярдәм күрсәтә белү;
- туган телгә карата олы хөрмәт уяту;
- эш барышында укытучы, укучы арасында бер-берсен аңлап төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен булдыру.

*Метапредмет нәтиҗәләр:*

- иҗади фикерләү, мөстәкыйльлек һәм башлап эш итү сәләтен үстерү;
- мәгълүматны эзләү һәм эшкәртү күнекмәләрен булдыру;
- куелган максат һәм бурычларга ирешә алу;
- логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйль эшләү мөмкинлеген үстерү.

**Эшчәнлек юнәлеше:** Укучыны әхлакый һәм гомуммәдәни яктан үстерү юнәлеше.

**Төре:** алган белемнәрне йомгаклау.
**Формасы:** уен.
**Дәрәҗәсе:** Мәктәп сәхнәсендә, ата-аналар алдында чыгыш ясау.

**1 нче алып баручы.** Исәнмесез!- диеп башлыйк әле.
Танышу бит шулай башлана.
Сезнең белән очрашканга, дуслар,
Күңелебез шундый шатлана.

Хәерле көн, хөрмәтле дуслар! Менә бүген без кышкы табигатьнең матур бер көнендә, сезнең белән бу якты залга бәйрәмгә килдек.

**2 нче алып баручы.** Бездә бүген туган тел бәйрәме. Бәйрәмебез “Тамчы шоу” дип атала. Бәйрәмнең үзәгендә - уңган, булган 6 нчы сыйныф укучылары. Каршы алыгыз. 6а сыйныфы төркеме (пауза), 6в сыйныфы төркеме (пауза), 6г сыйныфы төркеме. Алар бүген тел бәйгесендә көч сынашачаклар.

**1 нче алып баручы. “**Телен белгән – ил ачар” ди халык. Шушы бәйгедә ана телебезгә булган мәхәббәтебезне, олы ихтирамыбызны җыр, бию, уеннар аша белдерәбез.

**Җыр Бакирова Инзилә башкара.**

**2 нче алып баручы**. Арттырмыйм да, киметмим дә шуны бел,
Татар теле – энҗе-мәрҗән тулы тел.
Моңлы тел ул, нурлы тел ул – Туган тел.
Баш очымда кояш булып тора гел.

Һәр бәйгедә хөкемдарлар була. Алардан башка без эшебезгә нәтиҗә ясый алмаячакбыз. Таныш булыгыз. Безнең хөкемдарларыбыз: милли эшләр буенча директор урынбасары Гатауллина Р.А., татар теле укытучылары Сафиуллина Г.Р., Гарифуллина Г.Р., Гаптрахманова С.В., Габдрахимова А.Х.

**1 нче алып баручы.** Бәйгебезне төркемнәрнең үзләре белән таныштырып, бер-берсен сәламләүләре белән башлап җибәрәбез.

Сүз 6а төркеменә бирелә.
Сүз 6в төркеменә бирелә.
Сүз 6г төркеменә бирелә.

**2 нче алып баручы.** Беренче **“Мин башлыйм, син тәмамла” уены** тәкъдим ителә. Һәр төркемгә 3әр мәкаль әйтелә. Җавап бирә алмасагыз, башка команда кул күтәреп, җавап бирә ала.

**1 төркем.** Акылы кысканың (теле озын).
Үзеңне үзең мактама (кеше сине мактасын).
Ата –ананы тыңлаган адәм булган (тыңламаган әрәм булган).

**2 төркем.** Ялган сөйләгән тотылыр (дөресен сөйләгән котылыр).
Үз анасын зурлаган, (кеше анасын хурламас).
Җиде кат үлчә (бер кат кис).

**3 төркем.** Тырышлык - бәхет китерер (Ялкаулык ачтан үтерер).
Эш үткәч үкенүдә (файда юк).
Теле барның – (иле бар).

**1 нче алып баручы.** Ә хәзер төркемнәрнең игътибарлылыгын тикшерәбез. **“Хаталы сүзне тап”**уены. Һәр төркемгә мультимедиада сүзләр бирелә. Сез мондагы ялгышларны табарга тиешсез. Эш тиз һәм дөрес башкарылырга тиеш.

**1 төркем**. Сәләм, игътибар, кәгазь, ямле, бәһет, гәилә, сәгать, шигыр.

**2 төркем.** Әммә, тәкдим, хәйкәл, төньяк, сәнгат, шагирь, сурәт, халык.

**3 төркем.** Дөня, тәбигать, аляпкыч, хава, көньяк, каләм, хәрбер, шәхес.

**Җаваплары:**

**1 төркем**. Сәлам, игътибар, кәгазь, ямьле, бәхет, гаилә, сәгать, шигырь.

**2 төркем.** Әмма, тәкъдим, һәйкәл, төньяк, сәнгать, шагыйрь, сурәт, халык.

**3 төркем.** Дөнья, табигать, алъяпкыч, һава, көньяк, каләм, һәрбер, шәхес.

**2 нче алып баручы.** Тел дигән дәрья бар,
Дәрья төбендә мәрҗән бар,
Белгәннәр чумып алыр,
Белмәгәннәр коры калыр.

Әйдәгез әле, шул дәрьяның хәзинәләре белән танышыйк. Сүзнең тылсымлы көчен тагын күзәтик. Һәр сүзнең кадерен белергә өйрәник. Хәзер лексика бүлегендәге белемнәрегезне тикшереп карарбыз. Сезгә **фразеологизмнар бирелә. Сез аның мәгънәсен бер сүз белән әйтергә тиешсез.**

1. Белем эчү – (уку).
2. Утлы табага бастыру – (ачулану).
3. Учта эретү – (буйсындыру).
4. Таң калу – (соклану).
5. Тал чыбыгы ашату - (кыйнау).
6. Сабын күбеге очыру – (мактану).
7. Тетмәсен тетү – (әрләү).
8. Терсәкне тешләү – (үкенү).
9. Күз буяу – (ялганлау).

**1 нче алып баручы.** Сезгә парлы сүзләр бирелә. Сез шуларның һәр тамырын тәрҗемә итеп **юмористик характердагы сүзлек төзергә тиешсез.**

1. Күрше-тирә – (сосед – окрестность)
2. Ир-ат – (мужчина – лошадь)
3. Ут-күз – (огонь – глаз)
4. Язу-сызу – (писать – чертить)
5. Кеше-кара – (человек – смотри)

6. Урын-җир – (место – земля)
7. Җир-су – (земля – вода)
8. Ис-акыл – (запах – ум)
9. Уен-көлке – (игра – смех)
10. Кош-корт – (птица – червяк)
11. Хатын-кыз – (женщина – девочка)
12. Бала-чага - (ребенок – жалит)

**2 нче алып баручы.** Инде **пантомима уены** үткәрәбез. Һәр төркемгә ситуация бирелә. Сәхнәгә чыгып сүзсез генә бу ситуация күрсәтелә. Ә башка командалар аны әйтеп бирергә тиешләр.

1. Балалар бакчасында.
2. Урманда.
3. Зоопаркта.

**1 нче алып баручы. Метограмма уены.** Бирелгән сүзләрдән бер хәреф үзгәртү юлы белән берничә сүз ясарга кирәк.

Командалар эшләгән арада сүзне 5 сыйныф укучыларына бирәбез. **Татар биюе башкарыла.**

| 1 төркем | 2 төркем | 3 төркем |
|---|---|---|
| Йөз (көз, йөк) | баш (каш, баз) | бит (бик,кит) |
| Бер | кыр | сан |
| Йөзек | итек | тавык |
| Көлке | сөйлә | бала |

**2 нче алып баручы.** Хәзер һәр командага **сүзләр төзергә бирелә**.

1. Си- иҗеге кергән сүзләр.
2. Ки- иҗеге кергән сүзләр.
3. Ми- иҗеге кергән сүзләр.

Ә алар эшләгәндә **капитаннар конкурсы** үткәрәбез. Аларны сәхнәгә чакырабыз. Һәр капитанга **тизәйткеч** тапшырабыз. Кем тизрәк һәм дөрес әйтә, шул җиңүче була.

1. Ник калдырдың? (КЪ авазына)

    Күпме көттең
    Карлыганның
    Каралганын.
    Кара әле,
    Ник калдырдың
    Караларын?
    Кара карга
    Чүпләр, дисәң,

Калганнарын –
Карлыганга
Исе китми
Каргаларның.

2. Туган (ГЪ авазына)

Туганымның
Туганының
Туганы да
Миңа туган.
Нинди генә
Туган әле –
Нәкъ мин туган
Көндә туган.

3. Һәвәскәрләр. (Һ авазына)

Җырга һәвәс
Һания дә,
Һани да,
Һиндия дә,
Һидият тә,
Һади да.
Шул һәвәслек
Дуслаштырган
Һәммәсен...
Ә син?

**1 нче алып баручы.** Ә хәзер төркемнәрнең язган сүзләрен жюрига тапшырабыз.

Инде мультимедиага игътибар итегез. Анда бер сүз бирелгән. Кайсы төркем **шул сүздән күбрәк сүзләр төзер икән**? 1 минут вакыт бирелә. Башладык.

***Сәламәтлек***

Тәмамлыйбыз. Эшләр жюрига тапшырыла.

**2 нче алып баручы.** Инде **кызык сораулар** тукталышына да җиттек.

Бу бәйгедә сорау укыла. Кайсы төркем кулын тизрәк күтәрә, шул җавап бирә.

1. Алманың яртысы нәрсәгә охшаган? (Икенче яртысына).
2. Чиләккә башта нәрсә салалар? (Күз).
3. Бүрегенә чыпчык кунганда, каравылчы нишли? (Йоклый).
4. Бер имәндә өч ботак, ботак саен өчәр алма. Барысы ничә алма? (Имәндә алма булмый).
5. Нәрсәне күрү бик җиңел? (Кеше гаебен.)
6. Кайсы ай календарьда юк? (Һавадагы ай).

7. Патша кемгә баш ия? (Чәчтарашка).
8. Эт чаба дип чаба торган бөҗәк. (Бет).
9. Шулпа эчертә торган район. (Лаеш).
10. Казан артында нәрсә бар? (“н” хәрефе).
11. Мәскәүдә берәү дә юк, Казанда икәү. Ул нәрсә? (“а” хәрефе).
12. Казан башында нәрсә бар? (“К” хәрефе).
13. Кара диңгезгә төшкән таш нишли? (Юешләнә)
14. Казанның уртасында ни бар? (З авазы)
15. Каз судан чыккач нишли? ( Җиргә баса)
16. Кәҗәгә 1 яшь тулгач нишли? ( Икенче яшькә китә)

**1 нче алып баручы. “Ребус чишәбез”тукталышы**

**1. Р=к 2.**

**, 2 1 „ 5 2 , 50**

**(кебек) (шикелле)**

**3. 3 , 1, , 10**

**(өчен)**

**2 нче алып баручы.** Инде соңгы бәйгегә дә килеп җиттек. Һәр төркемгә **өй эше** бирелгән иде. Сәламәтлеккә багышланган мәкальләрне киңәйтеп хикәя язып килергә.

“Саулыкның кадерен белмәсәң, авыруга ачуланма”,
“Сәламәт тәндә – сәламәт акыл”,
“Тән рәхәте сәламәтлек, җан рәхәте – гыйлем”
Ягез, сүз 1 нче төркемгә бирелә.
2. төркем.
3 төркем.

**1 нче алып баручы.** Командалар ярышы
Калдыра безне хәйран.
Тик, кадерле балалар,
Иртәгә түгел бәйрәм.
Шуңа күрә шушы җирдә
Туктатабыз уенны.
Жюри әйтер: кемнәр алды
Иң беренче урынны.
Ә хөкемдарлар балларны санаган арада без җыр тыңлап үтәбез.

**Җырлый Юльметьева Аэлита.**

**Рефлексия.** Йомгаклау өчен сүз хөкемдарларга бирелә. Төркемнәр бүләкләнә.

**2 нче алып баручы.** Җиңүче, борыныңны чөймә!
Җиңелүче, борыныңны салма!

Безнең ярышларда җиңелсәң дә,
Тормыш ярышында җиңелмә!

**1 нче алып баручы.** Хушыгыз, дуслар, хушыгыз,
Тәмамланды “Тамчы шоу.”
Сезгә зур уңыш телибез,
Булыгыз сез һәрчак сау.

***Дәрестән тыш эшчәнлек эшкәртмәсе***
***(6 нчы шөгыль)***

**Тема:** Әкият сөйлим...

**Максат:** 1. Язучыларның әкиятләрен искә төшерү.
2. Әкияләрдә тапкырлык, зирәклек, батырлык салынуын аңлату.
3. Язучыларның әкиятләрен укыганда, өйрәнгәндә укучыларның акылын, хисләрен үстерү.

**Планлаштырган нәтиҗәләр:**

*Шәхес буларак УУГ*: язучыларның әкиятләре белән танышу, өлкәннәргә хөрмәт, үзара дуслык хисләре тәрбияләү;

*Метапредмет* :

*Коммуникатив УУГ*: яңалыклар таба, бергәләп эшли, эзләнә, үз фикерен тулы әйтә белү;

*Регулятив УУГ*: конфликтларны һәм каршылыкларны чишә алыр өчен ихтыяр көчен үстерү;

*Танып-белү УУГ*: танып-белү максатын билгели алу, әкиятләрдә күтәрелгән проблемаларны чишә алу һәм сорауларга тулы җавап бирә белү, кирәкле мәгълүмат туплау, эзләнүле һәм иҗади эш вакытында килеп чыккан проблемаларның чишү юлларын таба белү.

**Җиһазлау**: тема буенча презентация, балалар ясаган рәсемнәр күргәзмәсе, язучыларның китаплары, маскалар һәм костюмнар, ноутбук, смарт-такта.

**Методлар**: әңгәмә, рольле уеннар, укытучы сүзе, сорау-җавап.

**Төре:** белемнәрне гомумиләштерү.

**Формасы:** уенлы сәяхәт.

**Дәрәҗәсе:** берләшмәдә эш.

**Эшчәнлек барышы:**

(*Укучылар түгәрәкләнеп утырганнар*).

**Укытучы.** Хәерле көннәр балалар. Кәефләрегез ничек?

**Укучылар**. Кояшлы иртә кебек.

**Укытучы.** Борын-борын заманда яшәгән ди.... Нинди әсәрләр шулай башлана?

**Укучылар**. Әкиятләр.

**Укытучы.** Әйе, шулай башлана халык әкиятләре. Балалар, без сезнең белән күп әкиятләр укыдык. Без бүген шул әкиятләр иленә сәяхәт итәрбез, укыган әкиятләр-

не искә төшерербез. Әлбәттә, дәресебез гади дәрес түгел. Безнең дәресебез тылсымлы сәяхәт кебек. Димәк, дәрестә бик игътибарлы, бер-беребезне бүлдермичә, бер-беребезгә хөрмәт саклап, тулы җаваплар бирергә кирәк, ләкин үзегезне иркен хис итегез. Бик актив булырга кирәк булачак. Сәяхәтебезне башлыйбыз!

**Укытучы.** "Үзем турында" уены белән башласак, әйбәт булачак. (*Һәр бала үзенең исеме нәрсәне аңлатуын һәм беренче хәрефенә матур сүзләр әйтергә тиеш. Мәсәлән, минем исемем - Ләйсән, беренче язгы яңгырны аңлата, ягымлы һ. б.*)

**Укытучы.** Буталып беткән хәрефләрне тәртипкә китерсәгез, кирәкле сүзне табарсыз. (*Тукай, Алиш сүзләрен табалар*). Балалар, әйтегез әле, нинди сүз таптыгыз?

**Укучылар.** Тукай, Алиш.

**Укытучы.** Әйе. Дөрес таптыгыз. Алар кемнәр соң?

**Укучылар.** Язучылар.

**Укытучы.** Әкиятләр турында сөйләшә башлаган идек бит. Язучылар килеп керде дәрескә. Нигә икән, балалар?

**Укучылар.** Бу язучылар әкиятләр язганнар. Без бүген шул әкиятләр турында сөйләшербез.

**Укытучы.** Дөрес балалар. Габдулла Тукай, Абдулла Алиш, Фәнис Яруллин балалар өчен күп әсәрләр язганнар. Шулар арасында матур әкиятләр дә күп. Ә нәрсәгә кирәк соң әкиятләр?

**Укучылар.** Көчле һәм шәфкатьле булырга, алдашмаска, бер-береңә ярдәм итәргә, олыларны хөрмәт итәргә өйрәтәләр.

**Укытучы.** Дөрес балалар. Ә хәзер сезнең әкиятләр турында белемнәрегезне тикшереп алам.

1. Нинди әкият герое тарагын урлата?
   а) Зөһрә кыз;
   б) Су анасы;
   в) Убырлы карчык.
2. Бер капчык бүре башы тапкан геройлар?
   а) Төлке белән торна;
   б) Карга беән Шөпшә;
   в) Кәҗә белән Сарык.
3. Сер саклый белмәгән кош?
   а) Тавык;
   б) Каз;
   в) Үрдәк.
4. Бүрәнә күтәреп йөрүче урман сарыгы?
   а) Аю;
   б) Шүрәле;
   в) Дию Пәрие.

5. Гел сугышып торган кошлар?

а) Аглый белән Таглый

б) Тукмар белән Чукмар;

в) Сак белән Сок.

6. Ай белән дуслашкан кыз

а) Алсу;

б) Таңсылу;

в) Айсылу.

**Укытучы.** Укучылар, булдырдыгыз. Әкиятләрне беләсез. Менә искә дә төшердек. Хәзер без сезнең белән ике төркемгә бүленеп “Әкиятләр иленә” сәяхәткә чыгабыз. Безгә сәяхәтне башларга костюмнар һәм маскалар ярдәм итәр. Хәзер мин әйткән геройны беренче төркем табып алырга тиеш.

1. Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак;
   Шул тарак белән утыра тузгыган сачын тарап.

   (“Су анасы”)

2. Хәзер инде ул яңа киез итекләрне киеп, рәхәтләнеп йөри икән. Ләкин куян кызы җылы итекләргә өйрәнмәгән булган, ул алардан бик тиз туйган, салып ташлаган.

   (“Куян кызы”)

3. Китте болар. Бара, һаман бара, бара,
   Күренмидер күзләренә ак һәм кара,
   Бара болар. Күпме баргач, алла белә,
   Юл өстендә үлгән бүре башын таба.

   (“Кәҗә белән Сарык”)

4. Кош-кортлар хуҗаларыннан башка бер кич кунганнар, берни булмаган. «Икенче көнне дә кайтмас бу», — дип, алар хуҗаны чакырып кайтырга берәрсен җибәрергә булганнар.

   (“Сертотмас үрдәк”)

5. Балтасы кулда, егет эштән бераз туктап тора;
   Тукта, чү! Ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра.

   (“Шүрәле”)

6. Бер әбинең ике әтәче булган. Бу әтәчләрнең берсе — ак, берсе кара икән. Ул аларның икесен дә бертигез ярата икән.

   (“Чукмар белән Тукмар”)

7. Ике учы тулганчы төнбоек чәчәкләре җыйганнан соң, Ай, үзенең болыттан ишеп ясаган баскычының йомшак басмаларына сак кына баса-баса, күккә күтәрелә икән.

   (“Зәңгәр күлдә ай коена”)

**Укытучы.** Укучылар, сез булдырдыгыз! Ә хәзер бу геройларыбыз үзләрен иҗат иткән хуҗаларын табарга тиешләр. *(Г.Тукай, А.Алиш, Ф. Яруллин фотолары янына әкият геройлары килә.)*

**Укытучы.** Сәяхәтебез дәвам итә. Хәзер төркемнәргә әкиятләрдән өзекләр таратыла, аз вакыт эчендә сез сәхнәләштереп күрсәтергә тиешсез. *(Төркемнән бер бала әкиятне укый, калганнары уйныйлар.)*

1. “Койрыклар” - А.Алиш
2. “Урман әкияте” Ф.Яруллин

**Укытучы.** Тактада сез белгән, өйрәнгән әкият геройлары. Ләкин алар үз урыннарында түгел. Сез аларга булышырга тиешсез. (*Төркемнәрдә эш.)*

А Алишның “Чукмар белән Тукмар” әкиятендә әтәч белән тавык сугыша;

Ф Яруллинның “Зәңгәр күлдә ай коена” әкиятендә ай урынына күлдә кояш коена;

Г.Тукайның “Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш” әкиятендә дию Карәхмәтне трамвайга бәйләгән;

А.Алишның “Каз белән Аккош” әкиятендә аккош бәбкәсе урынына каз бәбкәсе велосипедта йөри;

Ф Яруллинның “Буар елан” әкиятендә елан урынына сукыр тычкан агачта утыра.

**Укытучы.** Инде без уйнадык та, артистлар да булдык, хәзер әйдәгез язучылар булып карыйк. Һәр төркем әкият уйлап язарга тиеш. (*Балалар әкият язалар. Әкиятләр укыла.*)

**Рефлексия**

**Укытучы.** Балалар, без дәрестән тыш чарада бүген ниләр эшләдек?

- Әкиятләр темасын кабатладык.

- Моның өчен нишләдек? ( *укыдык, сөйләдек, биедек, сорауларга җавап бирдек, текст төзедек.)*

Бүген бик тырышып эшләдегез. Рәхмәт! Бер-берегезгә рәхмәт әйтегез! Сез булдырдыгыз, балалар!

## Дәрестән тыш чара “Һөнәрләр дөньясына кереш” программасы буенча (10 нчы шөгыль)

*Нургалиева Гөлсинә Мидхәт кызы,*
*Казан шәһәре Мәскәү районы 94 нче гимназиянең*
*югары квалификацион категорияле*
*туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

**6 нчы сыйныф укучылары өчен төзелде.**

**Юнәлеше:** иҗтимагый (социаль).

**Төре:** хезмәт эшчәнлеге.

**Үткәрү формасы:** түгәрәк, төркемнәрдә эш.

**Дәрәҗәсе:** икенче дәрәҗә – җәмгыятьнең төп кыймматләренә,социаль чынбарлыкка карата укучының уңай мөнәсәбәт тәҗрибәсе алу. Укучыларның сыйныф дәрәҗәсендә үзара хезмәттәшлеге.

**Тема**: Һөнәрләр дөньясы.

**Белем бирү максаты**: Укучыларга төрле һөнәр ияләре һәм һөнәр үзенчәлекләре турында белем бирү, һөнәр сайлауда дөрес юнәлеш бирү.

**Фикерләү сәләтен үстерү максаты:** Аралашу осталыгы күнекмәләрен формалаштыру. Белем дәрәҗәсен, игътибарлылыкны, күзәтүчәнлекне, уйлау сәләтен үстерү.

**Тәрбияви максат**: Балаларда бер-берсе белән килешеп эшли белү, бергә эшләүнең нәтиҗәсен күрә белүне тәрбияләү. Туган якта эшләүче һөнәр ияләре белән таныштыру һәм аларга карата кызыксыну уяту.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Шәхескә кагылышлы:** төрле һөнәрләргә карата кызыксыну, һөнәр ияләренә карата хөрмәт хисләре уяту; эшчәнлекнең максаты һәм нәтиҗәсе арасында бәйләнешне билгели алу.

**Метапредмет:**

*Танып-белү УУГ*: танып белү мәсъәләсен аңлау, ирекле һәм аңлы рәвештә сөйли алу.

*Коммуникатив УУГ*: әйләнә-тирәдәгеләр белән хезмәттәшлек итә алу, әңгәмәдәшләрнең фикерләрен тыңлый һәм аңлый белү, коммуникатив максаттан чыгып, сүзләрне дөрес куллана, фикерне анык һәм аңлаешлы итеп җиткерә алу.

*Регулятив УУГ*: уртак эшчәнлек оештыра белү, үзләштерү өчен кирәкле материалны билгели белү.

**Җиһазлау:** интерактив такта, компьютер, иҗади эш өчен материал, карточкалар.

**Дәрестән тыш чара барышы**

1. **Кереш өлеш (Слайд 1)**

- Хәерле көн, укучылар. Хәлләрегез ничек?
- Бүгенге дәрестән тыш чараны мин видеороликтан башларга телим.Тактага карыйбыз.
- Укучылар, worldskills нәрсә ул? (эшче профессияләр чемпионаты)
- Без бүген нәрсә турында сөйләшәчәкбез, сез ничек уйлыйсыз?
- Бүгенге чараның темасы “Һөнәрләр дөньясы”

2. **Уку мәсьәләсен кую.**

Һөнәр сайлау – кеше тормышында иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе. Һәрбер кеше үзенең күңеленә хуш килгән һөнәрне сайлый һәм аңа гомерен багышлый Заман үзгәрә барган саен, тормыш яңа һөнәрләр таләп итә. Гомерлек юлны сайлау бик авыр һәм җаваплы эш.

Татарстан элек-электән осталары белән дан тоткан. Әйдәгез, без сезнең белән “Осталар шәһәре” булдырыйк.

Безнең шәһәребездә 4 остаханә эшли. Алар сезнең анкета нәтиҗәләре буенча төзелде.

- төзү остаханәсе – Төгәллек
- дизайн остаханәсе – Күзаллау (воображение)
- зәркән остаханәсе – Түземлек
- ашарга пешерү остаханәсе – Ис сизү

**3. Уку мәсьәләсе чишү.**

1) Укучылар, әйдәгез сезнең белемнәрне практикада кулланып карыйк.

Биремне аңлатам.

1 төркем – төзүчеләр, йорт макеты төзиләр һәм аны милли бизәкләр белән бизиләр.

2 төркем – зәркән._Алар татар кызлары өчен бизәнү әйберләре ясыйлар.

3 төркем – дизайнерлар. Татар орнаментларын кулланып, аксессуарлар җыелмасы ясыйлар.

4 төркем – пешекчеләр. Татар халык ашлары китабы төзиләр һәм үзләре теләгән ризыкның моделен ясыйлар.

Куелган бурычны үтәгәч, үзегез ясаган әйберне безгә тәкъдим итәсез. Уңышлар сезгә!

**4. Нәтиҗә ясау, йомгаклау.**

1. -Укучылар, әйдәгез, үзегезнең чара барышындагы эшчәнлекне бәяләгез әле. Һәр җавапны анализлау.

2. а) төркемнең эш нәтиҗәсе сезгә ошадымы?

-әйе;

-юк;

-җавап бирергә кыенсынам.

б) Кайсы төркемнең эше иң кызыклы?

- 1 2 3 4

в) Иҗади биремне үтәгәннән соң, сезнең фикерегез үзгәрдеме?

-әйе;

-юк;

-җавап бирергә кыенсынам.

г) Сезгә бүгенге чара ошадымы?

-әйе;

-юк;

-җавап бирергә кыенсынам

- Һөнәре булган, кулыннан эш килгән кешенең җирдә һәрвакыт үз урыны, үз юлы, үз һөнәр җимешләре була. «Тырышкан табар, ташка кадак кагар» дигән

мәкаль һөнәр белгән һәр кешегә туры килә. Һөнәрегез булса, авырлыктан курыкмасагыз, эш яратсагыз, сез үзегезне иң бәхетле кеше дип саный аласыз. Шуны онытмагыз: һөнәр сайлаганда сез үз язмышыгызны сайлыйсыз. Сайлаган һөнәрегез үзегезгә ошый һәм шатлык китерә торган булсын.

Һөнәрләр күп: кем булсаң да
Игенчеме, эшчеме?
Тик онытма бер нәрсәне:
Хезмәт бизи кешене.

Яраткан хезмәтең булу – зур бәхет. Бу бәхет сезне читләтеп үтмәсен, илгә-көнгә яраклы, туганнарыгызга, якыннарыгызга, гаиләгезгә кирәкле булып яшәгез дигән теләктә калам.

## Тел күрке – сүз

***(татар теле буенча 5 нче сыйныфта дәрестән тыш чара)***

*Шәгәрәева Алинә Илсур кызы,*
*Казан шәһәре Яңа Савин районы 13 нче татар гимназиясенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

***Дәрестән тыш чараның формасы:*** иҗади остаханә.
***Дәрестән тыш чараның юнәлеше:*** гомуми интеллектуаль.
***Дәрестән тыш чарага максатлар:***
*Эшчәнлек буенча:* эш гамәлләренә күнекмәләрне камилләштерү: сүзлек җыю, рәсемнәр белән эшләү, коллаж төзү; иҗади һәм сәнгати сәләтләрне үстерү.
*Эчтәлек буенча:* лексикология бүлеге буенча белемнәрне камилләштерү һәм гомумиләштерү.
**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**
***Шәхескә кагылышлы:*** туган ил тарихы белән бәйле мөһим датаны белү һәм горурлану, әхлакый сыйфатларның әһәмиятен аңлау, шәхси карар кабул итә белү.
***Метапредмет:***
*Танып белү УУГ*: эшнең асылын ачыклау һәм үз алдыңа максат кую, текстны кабул итү һәм аның эчтәлегендә ориентлашу, эшне җаваплы, аңлап башкару.
*Регулятив УУГ*: күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.
*Коммуникатив УУГ*: сыйныфташлар һәм укытучы белән эшне оештыруда хезмәттәшлек итү; эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыра алу; коммуникатив максатлардан чыгып, сүзләрне дөрес һәм урынлы куллану.

***Эшне оештыру:*** фронталь, индивидуаль, парларда, төркемнәрдә.

***Эшчәнлек төрләре***: әдәби-иҗади эшчәнлек, танып белү эшчәнлеге, уен эшчәнлеге.

**Дәрестән тыш чараның барышы:**

**I. *Оештыру, мотивлаштыру этабы***

*Укытучы:* Хәерле иртә, укучылар!

*Укучылар:* Хәерле иртә!

*Укытучы:* Кәефләрегез ничек?

*Укучылар:* Яхшы, рәхмәт!

*Укытучы:*Бер-беребезгә елмайыйк әле, укучылар, рәхмәт! Мин дә бүген, елмаеп-көлеп, сезнең белән очрашуга ашыгып килгәндә, каршыма бер китап килеп чыкты. Якынрак карасам – табышмаклар китабы. Балалар, ә сез табышмаклар яратасызмы?

*Укучылар:* Әйе.

*Укытучы:* Мин дә шулай дип уйладым һәм китапны үзем белән алырга булдым. Алып килгәнмен икән, берничә табышмак әйтми булмас сезгә. Ягез әле, уйлап карагыз.

1) Әйтермен – миннән китәр,
   Тыңламасаң - синнән китәр. (Сүз)
2) Бер чыгарып җибәрсәң,
   Нихәтле чакырсаң да кире кайтмый. (Сүз)
3) Авыз – капка, ачыла.
   Аннан нинди җил чыга? (Сүз)

*Укытучы:*Дөрес, укучылар, белдегез. Сүз дә сүз булды җаваплар. Димәк, бүген без сезнең белән нәрсә турында сөйләшербез?

*Укучылар:* Сүзләр турында.

*Укытучы:* Ә сүзләрне тел гыйлеменең кайсы бүлеге өйрәнә әле?

*Укучылар:* Лексикология.

*Укытучы:* Бик дөрес әйтәсез, укучылар. Мин сезне бүген лексикология темасы буенча “ Тел күрке - сүз” дигән иҗади остаханәгә чакырам. Остаханә нәрсә соң ул, укучылар? Анда нишлиләр?

*Укучылар:* Нәрсәдер эшлиләр, көйлиләр, ясыйлар.

*Укытучы:*Иҗади остаханә булгач, без бүген сезнең белән нишләрбез?

*Укучылар:* Иҗат итәрбез, иҗади эшләр белән шөгыльләнербез.

*Укытучы*. Эшне ике төркемдә оештырсак, җайлырак булыр дип уйлыйм. Сез минем белән килешәсезме?

*Укучылар:*Әйе.

**II. *Төп эшчәнлек этабы***

1. *Укытучы:* Игътибар белән экранга
Карагызчы, балалар.
Монда миннән сезгә бер
Кечкенә генә сюрприз бар.

***("Шаян-ТВ" студиясендә төшерелгән видео карау)***

*Укытучы:* Сюрприз ошадымы?

*Укучылар:* Әйе.

*Укытучы:* Укучылар, ә сез "Шаян-ТВ" каналын карыйсызмы соң?

*Укучылар:* Әйе, карыйбыз.

*Укытучы:*Рәхәт сезгә, укучылар. Сезнең туган телдә эшләүче махсус үз каналыгыз бар телевидениедә. Ә Рәзил абыегыз сөйләгән шигырь нинди сүзләр турында иде икән? Кайсы сүзтезмәләрне, дөрестән дә, тел бизәге дип әйтеп була?

*Укучылар:* Фразеологизмнарны.

*Укытучы:* Аңлавыгызча, без хәзер фразеологизмнар белән эшләрбез. Бер төркемгә фразеологик әйтелмәләр, икенче төркемгә аларның аңлатмасын өләшәм. Ә үзем алар белән бәйле рәсемнәр күрсәтәм. Туры китерик әле шуларны.

*(рәсем астына әйтелмәне һәм аның аңлатмасын ябыштырып, фразеологизмнар сүзлеген җыю)*

**2.** *Укытучы:* Фразеологик әйтелмәләрдән тыш, телебездә тормыштагы төрле гыйбрәтле күренешләрне гомумиләштереп, образлы итеп әйткән тапкыр гыйбарәләр дә бар. Ничек аталалар әле алар?

*Укучылар:* Мәкальләр.

*Укытучы:* Чираттагы эшебезне мәкальләр белән бәйләрбез. Һәрберегезгә берәр мәкаль өләшәм *(укучыларга мәкальләр язылган кәгазьләр өләшү).*Укып чыктыгызмы мәкальләрне? Аңладыгызмы?

*Укучылар:* Әйе. Аңладык.

*Укытучы:* Бик яхшы. Кабинетның төрле почмагында эленеп торган 4 рәсемгә игътибар итегез әле, укучылар. Кайсыгызның мәкале шул рәсемгә туры килә? Табыгыз әле.

*(рәсем белән мәкальне берләштерү, уку, мәгънәсен аңлату)*

*(конэрс алымы буенча эшләү)*

**3.** *Укытучы:* Утырырга ашыкмыйк әле, укучылар. Әйдәгез, бер уен уйнап алыйк. Уеныбыз гади түгел, башны да эшләтә торган.

Минем кулда серле капчык,
Ә капчыкта бар сүзләр.
Шул сүзгә мәгънәдәш сүзне
Әйтергә кирәк сезгә.

Бер-берсенә якын мәгънәле, ягъни мәгънәдәш сүзләрне ничек атыйбыз әле?
*Укучылар:* Синонимнар.
*Укытучы:* Музыка дәвамында, капчыкны бер-беребезгә бирешеп уйнарсыз. Музыка туктаганда, капчык кемдә кала, шул укучыга капчыктан бер сүз алып, шул сүзнең синонимын әйтергә кирәк булыр.

*(уйнау, сүзләрнең синонимнарын әйтү)*

**4.** *Укытучы:* Бигрәк оста сез, балалар. Синонимнарны да әйбәт беләсез. Инде утырып ял итегез. Ә мин сезгә бер мәзәк сөйләп алам.
*Ике малай сөйләшә, ди. Берсе әйтә*:
- *Бездә өч бассейн төзеделәр: берсе салкын сулы, икенчесе җылы сулы, өченчесе бөтенләй сусыз.*
*Икенче малай гаҗәпләнеп сорый:*
-*Ә сусызы ни өчен?*
-*Йөзә белмәүчеләр өчен.*
Шундый бассейннар да бармы икән, укучылар? Юктыр, мөгаен, чөнки бу мәзәк кенә. Ә мәзәктә очраган *сулы – сусыз, җылы сулы – салкын сулы* дигән сүзләр нинди мәгънәне белдерә икән, укучылар?
*Укучылар:* Капма-каршы.
*Укытучы:* Ә капма-каршы мәгънәле сүзләр ничек атала әле?
*Укытучы:* Антонимнар.
*Укытучы:* Бик дөрес әйтәсез укучылар. Инде антонимнар белән дә эшләп алыйк. Һәр төркемгә берәр шигырь бирәм. Шигырьләрне бераз тәртипкә салырга кирәк. Моның өчен, шагыйрь булырга кирәкми, калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең антонимнарын язу җитә.

*(шигырьләрне төзекләндерү, капитаннар чыгып укый)*

*Укытучы:* Балалар, бу шигырьләр нәрсә турында?
*Укучылар:* Бөек Ватан сугышы, Җиңү бәйрәме турында.

*(шигырьләр язылган кәгазь битләре артындагы рәсемнәрне берләштерү)*

*Укытучы:* Быел 9 нчы майда без Җиңүнең ничә еллыгын билгеләп үтәбез әле?
Укучылар: 75 еллыгын.

*(тематик видео карау)*

*Укытучы:* Укучылар, бәйрәм көннәрендә генә түгел, без һәрвакыт әлеге җиңүнең ниди зур корбаннар хисабына бирелгәнен хәтердән чыгармаска тиеш. Туган иле өчен яу кырында ятып калганнарга, арабыздан киткән ветераннарга – мәңгелек хәтер!
5. *Укытучы:* Менә без эшебезнең йомгаклау өлешенә дә килеп җиттек, укучылар. Эшебезне гомумиләштерик инде. Һәр ике төркемгә дә менә шундый терәк

материал өләшәм. Шулардан файдаланып, лексикология бүлеге буенча коллаж ясап карыйк. Музыка белән эшләргә күңеллерәк булыр.

*(төркемнәрдә коллаж җыю, эшләрне тәкъдим итү)*

### *III. Рефлексия*

*Укытучы:*Дәрестән тыш чарабыз ахырына якынлаша, укучылар. Сезгә ошадымы ул?

*Укучылар:* Әйе.

*Укытучы:* Ә кайсы моментлары аеруча ошады? «Өч М» үрнәге буенча, дәрестән тыш чара дәвамында, сезнең аеруча уңышлы килеп чыккан өч моментны атагыз әле.

*(укучылар җавабы)*

*Укытучы:* Рәхмәт, укучылар. Ә хәзер, гомумиләштереп, үзегезнең бүгенге эшне кабул итү халәтенә туры килгән әйтелмәне сайлап алыгыз әле:

- *Бер колактан керде, икенчесеннән чыкты;*
- *Баш тубал кебек;*
- *Суга җибәргән балык кебек;*
- *Авыз колакта;*
- *Биш бармагым кебек беләм.*

*(укучылар җавабы)*

*Укытучы:* Рәхмәт, укучылар. Дәрестән тыш чарабыз тәмам. Сау булыгыз!

## Тема: “Әйтем — сүзнең бизәге, мәкаль — сүзнең җиләге”

*Сөнгатуллина Рузилә Фаиз кызы,*
*Казан шәһәре Совет районы 141нче гимназиянең туган*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Юнәлеше**: гомуми интеллектуаль.

**Төре**: танып белү.

**Формасы**: түгәрәк.

**Максаты:** мәкальләрнең халык авыз иҗатында ролен аңлау.

**Бурычлар:**

1) халык авыз иҗаты әсәрләре арасында бәйләнешне карау, барысында да татар халкының тәҗрибәсе, тормышы, зирәклеге чагылышын күрү;

2) мәкальләрнең эчтәлеген аңлап, сөйләмдә куллану;

3) мәкаль аша фикерне кыска әйтү күнекмәсен үстерү.

**Чыганаклар:** презентация, татар халык җыры “Күбәләк”, таратма материал “биремнәр”.

***<u>Дәрестән тыш эшчәнлекнең барышы.</u>***

I. **Уку эшчәнлегенә уңай мотивация тудыру.** Бәйрәм татар халык җыры “Күбәләгем” белән башланып китә. Көй башта көчлерәк яңгырый, аннан тавышы кими төшә.

- Укучылар, бу җырны таныдыгызмы/ беләсезме? Сүзләре сезгә танышмы? Бу җырның исеме ничек? (“Күбәләгем”)

- Ә кайсыгыз әйтә алыр икән, бу җырның сүзләрен кем язган? Аның авторы бармы?

- *Аның авторы юк (халык язган).* Авторы билгесез җырларны/ әсәрләрне нинди әсәрләр дип йөртәләр?

- *Халык авыз иҗаты әсәрләре.*

- Әйе, татар халык авыз иҗаты әсәрләре. Ә сез халык авыз иҗаты әсәрләрен беләсезме? Анда нинди жанрлар бар?

- *Әкият, такмак, табышмак, мәкаль, әйтем, санамышлар, сынамышлар, җырлар, риваятьләр һәм башкалар.*

- Тактага игътибар итегез әле (презентациядә мисаллар чыгып бара). Ә бу мисаллар халык авыз иҗатының кайсы төрләренә карый?

1) Борын-борын заманда бер хатын яшәгән ди. Аның өч кызы булган. Бу хатын кызларымның тамаклары тук, өсләре бөтен булсын дип эшләгән дә эшләгән... ***(Әкият)***

2) Әке - бәке, кыек сәке эремчек,
Син калып тор, энем чык. **(санамыш)**

3) Җәен – соры, кышын – ак,
Аңа шулай яхшырак. ***(табышмак)***

4) Әлли — бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу,
Бәү — бәү итеп, күз йомып,
Изрәп кенә китәр бу.
Алма кебек тәгәрәп,
Үсеп буйга житәр бу,
Абыйлары артыннан
Мәдрәсәгә китәр бу. ***(бишек җыры)***

5) Әйтем – сүзнең бизәге, мәкаль – сүзнең җиләге.

***<u>III. Чарага максат һәм бурычлар кую.</u>***

- Ә бу матур сүзләрне кайсы жанрга кертербез. *(мәкаль)*

- Сез аларны тагын кайда күрәсез. (*мәкаль, тактага язылган*)

- Димәк, без бүген татар халык авыз иҗатының кайсы жанрына тирәнрәк/ күбрәк тукталырбыз. (*мәкальләр*)

- Сез мәкальләр белән күбрәк кайсы дәресләрдә очрашасыз? *(татар теле, әдәбият, рус теле дәресләрендә)*

- Әйтегез әле, ә нәрсә соң ул мәкаль?
- *Мәкаль – акыл бирү, сөйләмне матурлау өчен кулланыла торган, кыска, тирән мәгънәле халык авыз иҗаты әсәрләре.*
- Ә әйтемнәр турында нәрсәләр беләсез?
- *Әйтемнәр аларга бик якын торалар. Әйтемнәр – образлы фикер йөртүгә корылган, күчерелмә мәгънәдә кулланылалар.*
- Бик дөрес.
- Димәк, без бүген сезнең белән татар халык авыз иҗатының кайсы жанры турында сөйләшербез *(мәкальләр).*
- Кабат мәкальнең асылына төшеник әле. Мондый сүзләрне, әйтемнәрне кыскача/ бер сүз белән ничек атап була?
( *Акыллы сүзләр).*
- Ә мондый акыллы сүзләрне, мәкальләрне күбрәк нинди кешеләр куллана? (*Акыллы, зирәк, белемле)*
- Берәрегез белмиме? Элек андый кешеләрне халык ничек атаган? (*Аксакаллар*)
- Ни өчен аларны шулай атаганнар икән? Ныгытыйк әле, сөйләп китегез әле (*балаларның җаваплары*).
- Әйе, укучылар, элек һәр авылның Аксакалы булган. Авылда чәчү башланыр алдыннан да, зур эшләр эшләгәндә дә, аларның рөхсәтеннән башка эш башламаганнар. Алар җир өлгергәнен караганнар. Хәзер дә зур чараларны безнең олы җитәкчеләребез башлый, хәер-фатиха бирә. Аларның сөйләмендә дә бу сүзләр еш очрый. Без дә мәкальләрне Аксакал киңәшләре итеп кабул итик, әйдәгез, һәр мәкаль – кызыклы фикер һәм файдалы киңәш булсын! Әйдәгез, без дә чарабызга кереп китү өчен Аксакалдан хәер-фатиха алыйк әле! (Аксакал белән видеоны карап китү)

***IV. Төп өлеш.***

**1. Күңелле тест.**

- Әйдәгез, ә хәзер кечкенә генә күнекмә-уен үткәреп алабыз. Хәзер мин сезнең игътибарыгызга күңелле тест тәкъдим итәм. Әйтем-мәкальләрне яхшы беләбезме икән? Тикшереп карыйк әле. Сездән кыска җаваплар көтәм.
Агачны яфрак бизи, ә кешене? **(хезмәт)**
Киемгә карап каршы алалар, ә нәрсәгә карап озаталар? **(акылга)**
Бүгенге нәрсәне иртәгә калдырма? **(эшне)**
Нинди эшкә кар ява? **(калган эшкә )**
Нәрсә беткәч, уйнарга ярый? **(эш)**
Нинди башка таяк кирәкми? **(акыллы)**
**Нәтиҗә: Әле ишеткән мәкальләрдән нинди сабак алдык? Кешене нәрсә бизи? (хезмәт) Башта нишләргә кирәк? (эшләргә) Кайчан ял итәргә ярый? ( эш беткәч)**

**- Әйе, балалар, аксакалларыбыз акылга, эшкә зур әһәмият биргәннәр. Баштан эш, аннан соң ял ди татар халык мәкале.**

**2. Командаларга бүленү.**

- Балалар, хәзер мин сезгә төрле мәкальләр өләшәм. Сез аларга күз йөртеп алыгыз да һәм матур итеп укып бирегез әле. Бер-берегезне игътибар белән тыңлагыз, темасын ачыкларга тырышыгыз.

Үз илем - алтын бишек.
Туган ана бер – туган Ватан бер.
Туган илем - туган анам.
Туган җирдәй җир булмас,
Туган илдәй ил булмас.
Туган илнең кадерен читтә йөрсәң белерсең.
Туган-үскән җирдән дә матур җир булмас.
Һәр гөл үз сабагында чәчәк атар.
*Матурлык - бер көнлек, дуслык - гомерлек.*
*Кешенең иң зур дәүләте - чын дусты.*
*Йөз сумың булганчы, йөз дустың булсын.*
*Кош канаты белән, кеше дуслык белән көчле.*
*Дуслык тау күчерә.*
*Дустың булмаса – эзлә, тапсаң – югалтма.*
*Балык сусыз, кеше дуссыз тора алмый.*

- Бу мәкальләр нәрсә турында *( туган ил һәм дуслык турында*)

**Нәтиҗә: Димәк, ата-ана, туган тел белән беррәттән кеше өчен тагын нәрсә бик кадерле? (*Туган ил*)**

**- Кешенең зур байлыгы кем икән? (*дусты, дуслары*)**

- Ә хәзер кемнәргә туган ил турында мәкальләр эләкте, алар (*Туган ил командасы*) уң якка, кемнәргә дуслык турында мәкальләр эләкте – алар (*Дуслык командасы*) сул якка утыралар. Без шулай итеп ике командага бүленеп бераз йөгерек фикер йөртеп, мәкальләр ярышы оештырып алырбыз.

**3. “Урынын тап”.**

- 1 тур “Урынын тап” дип атала. Мин хәзер сезгә мәкальләр язылган карточкалар таратам. Ләкин ул мәкальләрдәге сүзләрнең урыннары буталган. Сезгә шуларны дөрес итеп урнаштырырга кирәк булачак. Кайсы төркем мәкальләрне тизрәк төзеп бетерә. *Төрле мәкальләр бирелә, һәр төркемгә 2 шәр мәкаль.*

Карточкалар:

- ***яхшырак, иптәшең, булсын, үзеңнән.***
- ***байлык, чын, зур, дуслык.***
- ***көчле, канаты, белән, кеше, белә, кош, дуслык.***
- ***бүре, аерылганны, ашар, ашар, бүленгәнне, аю.***

(*тактада мәкальләрнең дөрес варианты чыга бара) (икешәрләп бирергә)*

**Нәтиҗә: Аксакал киңәшләре бу юлы ни турында сөйли? Дустың нинди булырга тиеш? (*Кыю, акыллы, гадел, тугры, үзеңнән яхшырак)* Нинди матур киңәшләр!**

**4. "Түгәрәк мәкаль"**

- Ә хәзер сезнең игътибарга менә шундый түгәрәк мәкаль тәкъдим итәм. Түгәрәк буенча мәкаль язылган. Аны укыр өчен мәкаль кайсы урыннан башланган, шул хәрефне табарга һәм укып бирергә кирәк.

Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс.

Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

**Нәтиҗә: - Димәк, аксакаллар эш, хезмәт турында ни дигәннәр?**

**Нинди кеше бөтен эшне дә булдыра ала? (*тырыш кеше)***

**Нинди кеше тормышта югалып калмый (*Һөнәрле кеше яши ала, яши белә, тормышта югалып калмый)***

**5. "Кыскалыкта осталык"**

- Балалар, алдагы мәкальләрнең фикере кыскача гына рәсемнәргә яшеренгән (кереп оялаган). Игътибар белән карагыз әле, бу рәсемнәргә карап, сез төркемнәрдә бергәләп фикер йөртегез әле! Монда нинди мәкаль турында сүз бара икән?

1) Җиде кат үлчә, бер кат кис.

2) Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын.

**Нәтиҗә: Димәк, Аларда фикер аз сүз белән белдереләме, әллә күп сүз беләнме?**

**(*Мәкальләр, кыска, үткен фикерне белдерәләр*)**

**6. "Русча ничек?"**

- Балалар, безнең татар һәм рус телләрендә охшаш, тәңгәл мәгънәле мәкальләр байтак. Алар бер үк мәгънәне белдерәләр. Алдагы бирем сездән татарча гына түгел, аларның русча эквивалентларын белүегезне дә сорый. Сезнең өстәлләрегездә зәңгәр кәгазьләрдә әлеге мәкальләр язылган.Хәзер бергәләп уйлашып, шуларның русча эквивалентларын табып карыйк.

Белем — нур, белмәү — хур. *(Ученье– свет, неученье – тьма)*

Китап – белем чишмәсе. *(Книга – источник знаний)*

Күп укыган күп белер. *(Кто много читает, тот много знает.)*

Белемдә көч. *(Знание –сила)*

**Нәтиҗә: Димәк, аксакаллар белемгә нинди бәя биргәннәр? Белемле кеше – нинди кеше? (*көчле кеше, акыллы кеше, зирәк кеше*)**

**7. "Пантомимо".**

- Сезнең өстәлләрдә **кызыл** кәгазьләр ята, аларда мәкальләр язылган. Сез аларны ничек уйнап күрсәтер идегез. **Бирем:** мәкальләрне пантомимо рәвешендә

сүзсез уйнап күрсәтергә, ә икенче каршы як команда нинди мәкаль турында сүз барганын белергә тиеш.
1) Бәхетне юлдан эзләмә, белемнән эзлә.
2) Ашаганда колагың селкенеп торсын, эшләгәндә йөрәгең җилкенеп торсын.
**Нәтиҗә: - Рәхмәт, укучылар, бик оста күрсәтә алдыгыз. Карагыз әле, мәкальләр безне уйларга, фикер йөртергә, башны эшләтергә дә мәҗбүр итәләр икән бит.**

**8. Серле саннар.**

-Укучылар, әлеге бәйге серле саннар дип атала. Сезнең нинди саннарны мәкальләрдә очратканыгыз бар.
- 100/ 7/1... саннары нәрсәне белдерә икән? (*җаваплар*) Ә хәзер саннар кергән мәкальләр белән эшләрбез.
Сезнең өстәлегездә саннары төшеп калган мәкальләр. Игътибар белән карагыз да тиешле саннарны куеп языгыз әле.

1) *... кат үлчә,... кат кис.*
2) *Батыр бер үләр, куркак... үләр.*
3) *... сум акчаң булганчы,... дустың булсын.*
4) *... куян артыннан кусаң, берсен дә тота алмассың.*
5) *... галим йөз наданны җиңәр.*
6) *Бер күктә... ай булмас.*
7) *... тәкә башы бер казанга сыймас – сөзешерләр.*
8) *... аяклы ат та абына.*

*(командалар мәкальләрне чиратлашып укыйлар)*
**Нәтиҗә: Димәк, мәкальләрдә саннарның үз мәгънәсе бар. Нинди мәгънәләрне белдерә икән бу саннар, әйдәгез, уйлап карыйк әле.**
Нинди сан уйлап эш йөртергә куша? (7)
Нинди сан күплекне белдерә? (100)
Бер-ике саннары нигә гел бергә йөри? (чагыштыруны белдерәләр)

**IX. Рефлексия.**

– Укучылар, без бүгенге чарабызда күпме мәкальләр ишеттек, бәлки кемнәрдер яңаларын да ишеткәндер. Сезгә бу Аксакал киңәшләре, аның үткен фикерләре ошадымы?
- Ә кайсыларын сез истә калдыра алдыгыз? Хәзер без сезнең белән “Аукцион” оештырып алырбыз. Кайсы команда күбрәк мәкаль истә калдырды икән? “Дуслык” командасы башлый, “Туган ил” командасы дәвам итә. Чиратлашып берәр мәкаль әйтәбез. Кайсы команда күбрәк мәкаль әйтә алыр икән? (*мәкальләр әйтешү*)
- Афәрин, балалар! Сез бик күп мәкальләр беләсез/ истә калдыргансыз икән, киләчәктә дә аларны онытмагыз, сөйләмегездә кулланырга тырышыгыз!
- Ә хәзер шушы мәгълүмати графикага карап, кыскача, бүгенге чара буенча нәтиҗә ясыйк әле. (*тактада презентациядә мәгълүмати графика*)




- Димәк, мәкаль жанр ягыннан нинди әсәр ул?
  - **мәкаль – ул ата-бабайлар сүзе, халык тәҗрибәсе һәм акылы**

- Мәкальләр безне нәрсәгә өйрәтә, теге яки бу эшне эшләгәндә нәрсә бирә?
  - **мәкальләр безгә киңәш бирә, безне яшәргә өйрәтә**

- Мәкальләрдә бер генә кешенең фикере чагыламы?
  - **анда бөтен халык өчен булган уртак фикер чагыла**

- Мәкальләрдә нинди фикер чагылыш тапкан?
  - **үткен фикер, алар тел байлыгы булып торалар**

- Мәкальләрне башка әдәби сәнгать әсәрләре белән янәшә куеп буламы
  - **мәкальләр - сәнгать әсәре**

- Мәкальләрдә нинди тормыш сурәтләнә: үткәнме, хәзергеме, киләчәкме
  - **мәкальләр – тарих, кешеләрнең үткән тормышын, тәҗрибәсен чагылдыра**

- Күрәсезме, балалар, телебез нинди бай һәм хикмәтле. Без дә үзебезнең телебездә рәхәтләнеп сөйләшеп яшик, аны югалтмыйча, онытмыйча, киләчәк буыннарга тапшырыйк. Үзебезнең туган татар телебезне кадерлик, саклыйк.

## Кояшлы ил – безнең ил
## (ТАССР оешуга – 100 ел тулу уңаена дәрестән тыш чара)

*Әхтәмова Гөлназ Мингали кызы,*
*Казан шәһәре Совет районы 175 нче гомуми урта белем мәктәбенең*
*югары категорияле туган тел һәм әдәбият укытучысы*

**Төркем: 6 нчы сыйныф укучылары**
**Эшчәнлек юнәлеше: гомуминтеллектуаль, рухи-әхлакый**
**Эшчәнлек формасы: клуб**

Эшчәнлекнең **планлаштырылган нәтиҗәләре**:

**Шәхескә кагылышлы**: туган ягыбыз аның тарихына, мәдәниятенә карата патриотлык, горурлык хисе, эшчәнлектә бер-береңә карата ихтирам хисе тәрбияләү.

**Метапредмет нәтиҗәләре**: эшчәнлекне планлаштыра белү, туган ягыбыз турында булган белемнәрне киңәйтү, эзлекле һәм логик фикер йөртү, мөстәкыйль рәвештә карарлар кабул итә белү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, проект эшчәнлеге тәҗрибәсен яклау.

**Җиһаз:** компьютер, мультимедиа проекторы, презентация, музыка, Татарстан картасы, Татарстан шәһәрләре рәсемнәре, төрле төсле карточкалардагы биремнәр, рәсем.

**Дәрестән соң эшчәнлек барышы**.

**Оештыру өлеше**

Укучылар төркемнәрдә укытучыны каршы алалар. Укытучы исәнләшкәннән соң утырышалар.

-*Укытучы*. Исәнмесез, укучылар.Без сезнең белән туган якны өйрәнүчеләр клубына җыелдык. (*музыка*) Чараны башлап җибәрәбез.

*Укытучы*. Ой, компьютер хата чыгара. Компьютер эшләп китсен өчен кодлы сүз әйтергә кирәк. Берәрегез белмиме? Хикмәт ребуста икән бит. Әйдәгез бергәләп, бирелгән ребусны чишик. (*Тактада ребус: Кояшлы ил- безнең ил)*

- *Укытучы*. Димәк, укучылар нәрсә турында сөйләшербез?

-*Укучылар*. Кояшлы илебез турында - Татарстан, Казан турында.

-*Укытучы*. Мин сезне автобуста сәяхәткә чакырам. Бирелгән маршрут буенча без хәрәкәт итәрбез. Иң соңгы тукталышта безне нәрсә көтә икән?

-*Укучылар*. Хәзинә.

-Укытучы. Бу хәзинәне сез табарга әзерме?

-*Укучылар*. Әзер.

-*Укытучы*. Биремнәрне фронталь, парларда да, төркемнәрдә дә эшләрбез. Төркемнәрдә эшләгән вакытта үзара киңәләшеп, ярдәмләшеп дөрес матур җөмләләр белән җавап бирергә тырышырбыз.

*Укытучы*. Укучылар, басабыз, автобуска кереп, урындыктагы яшел төсле карточкаларны алып утырабыз.Әйдәгез, ременьнәрне каптырабыз. Киттекме?

-*Укучылар*. Киттек.

**Төп өлеш.**

-*Укытучы*.Укучылар, без нинди тукталышта?

-*Укучылар*. **"Уйла, фикерлә"** тукталышында.

-*Укытучы*. **Ал төсле карточкаларда сораулар бирелгән, әйдәгез парларда киңәшләшеп алабыз.**

Башладык. 1 нче пар. Берегез сорауны укый, икенчегез җавап бирә.

1. Татарстан Республикасының башкаласы нинди шәһәр? Татарстанның символларын әйтегез.
2. Татарстанның беренче һәм хәзерге президентын атагыз.
3. Татарстанның иң зур байлыгы нәрсә? Ул кайда чыгырыла?
4. КамАЗ машинасы кайсы шәһәрдә җитештерелә?
5. Татарстанда 2019 нчы елның август аенда нинди зур вакыйга булачак?
6. ТАССР 1920 нче елда оешкан. Бу вакыйга үзенең 100 еллыгын кайчан билгеләп үтәчәк?

-*Укытучы.* Афәрин, бик дөрес җавап бирдегез. Юлыбызны дәвам итәбез.
- Безне нинди тукталыш көтә?
-*Укучылар.* **“Саннар безгә ни сөйли**” тукталышы.
-*Укытучы.* Төз итеп утырабыз. Каешлар турында онытмыйбыз. Әйдәгез киттек! Бу тукталышта безгә Татарстан турында җөмләләр бирелгән, ә саннары төшеп калган. (*Смарт такта куллану*). Әйдәгез, аларны урыннарына урнаштырабыз. Кул күтәреп җавап бирәбез һәм тиешле урынга күчереп куябыз.
Татарстанның мәйданы: 68,0 мең. кв. км.
Татарстанда 21 шәһәр, 43 район бар.
Республикабызда 4 зур елга ага: Идел, Кама, Нократ, Агыйдел.
Халык саны: якынча 4 млн кеше.
Республикада 115 милләт вәкиле дус һәм тату булып яши.
*Укытучы.* Афәрин, булдырдыгыз. Киләсе тукталыш нинди? Автобуска җайлап утырдык, ременьнәрне каптырабыз. Киттекме? (*Автобус тавышы*). **Менә “Иҗат бакчасында**” тукталышына килеп тә җиткәнбез. Монда без шигырь язу сәләтен эшкә җигәрбез. Басабыз. Урыннарга утырабыз. **Сары төсле** карточкаларны алабыз. Бу биремне төркемнәрдә үзара киңәшләшеп, бирелгән шигырьнең дәвамын язып бетерәбез. Башладык.

Туган ил ул —әти-әнием,
Туган ил ул — минем гаиләм.
Туган ил ул — минем мәктәбем,
Туган ил ул — якын дусларым.
Туган ил ул — шәһәр, авыллар,
Туган ил ул — елга, урманнар.
Туган ил ул —якын туганнар,
Туган ил ул — туган нигезләр.

- *Укытучы* Тәгәлләдек. Беренче төркем әйдәгез әле, шигырегезне укып бирегез.
- *Укытучы* Афәрин! Икенче төркем, әйдәгез сезне тыңлыйбыз. Әйе, укучылар туган илебез ул әти-әнидәр дә, туганнар да, дуслар да, мәктәбебез дә, урамыбыз да.
- *Укытучы* Булдыргансыз!

- *Укытучы* Ике төркемгә дә бирем! 1 нче төркем сез шигырьне шатлык интонациясе белән, 2 нче төркем, ә сез горурлык белән укып күрсәтегез әле.

- *Укытучы* Әйдәгез!Афәрин. Укучылар бирем бераз катлаулана. Бу шигырьләрне рэп итеп җырлап карарбыз.

- *Укытучы* Ә сезнең рэп җырлаганыгыз бармы? Рэп җырлаганда безгә куллар да ярдәмгә килә, шулай бит. Без дә бөтен шартына туры китереп әйдәгез җырлап карыйбыз. (*Укучылар җырлый).* Кул чабыйк әле, ничек матур җырладыгыз.

-*Укытучы.* **Киләсе тукталыш. "Кунакка рәхим итегез"**. Казанга килгән туристлар саны елдан –ел арта.Татарстаныбызның даны үскәннән – үсә бара. Экскурсияләрне кем оештыра дип уйлыйсыз?

-*Укучылар.* Экскурсоводлар.

-*Укытучы.* Әйе, бик дөрес. Күз алдына китерегез: сезгә дә экскурсоводлар роленә кереп карарга туры киләчәк. Кунакка киләсе туристларны Татарстан белән таныштырып, кыска гына проект-презентация ярдәмендә бергәләшеп сөйләп китәрсез. Моның өчен конвертта бирелгән рәсемнәрне кулланырсыз. Өстәлдә яткан конвертларны алдык. 2-3укучы проектыгызны тәкъдим итәр. Сез кунакларны ТАССРның 100 еллыгына кунакка чакырырсыз. Икенче төрле әйтсәк, димәк, без реклама ясыйбыз. Тукталышларда алган белемнәрне дә кулланып, эшегезне киңәшләшеп башкарырсыз. Башладык. (*Документкамера аркылы проектны күрсәтү*)

- *Укытучы*. Әйдәгез. Беренче төркем. Икенче төркем сезне тыңлыйбыз.

-*Укытучы*. Афәрин, бүгенге чарада сез бик актив эшләдегез.

Сездән чын экскурсоводлар чыга икән бит. Кул чабып алыйк әле. Әйтегез әле, һәрбер турист истәлеккә нәрсәләр алып китәргә мөмкин.

-*Укучылар.* Сувенир, бүләк, чәкчәк һ.б

-*Укытучы.*Менә сандыкны ачар вакыт җитте. Монда нәрсә яшеренде икән? *(сувенирлар- магнит, значок, чынаяк, блокнот һ.б.)*

- Әйдәгез карыйбыз.(*Сандыкта магнитлар*). Бу кечкенә генә бүләкләр бүгенге чарабызның истәлеге булып калыр дигән теләктә калам.

**-Рефлексия.**Тактада өч дәрәҗәле баскыч бирелгән. Бүгенге чарада алган белемнәргә таянып, сез Татарстан турында кайларда чыгыш ясый алыр идегез? 1.Сыйныф, 2.Мәктәп күләменд,. 3.Район, шәһәр, республика күләмендә. Укучылар мин сезнең актив булуыгызга бик шат. Үз-үзегезгә ышанычыгызны беркайчан да югалтмагыз. Һәрвакыт шундый актив, ачык булыгыз дигән теләктә калам.

**Йомгак.**

-*Укытучы.*Туган телебездә бик матур сөйләшәсез. Җавапларыгыз өчен сезгә бик зур рәхмәт. Шуның белән чарабыз тәмам. Сау булыгыз.

**Тема: Муса Җәлил-балаларның якын дусты**

(Шагыйрь иҗатына багышланган тамчы – шоу.
Дәрестән тыш эшчәнлекнең гомуминтеллектуаль юнәлеше)

*Галәветдинова Ләйсән Габделәхәт кызы, Ибраһимова Энҗе Сәлим кызы,*
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 62 нче урта*
*гомуми белем мәктәбенең туган (татар) тел укытучылары*

**Эшчәнлекнең төре:** танып-белү.
**Эшчәнлекнең формасы**: уен.
**Эшчәнлекнең дәрәҗәсе**: мәктәп күләмендә ачылу.
**Максат:** 1.Балаларның Муса Җәлил тормышы һәм иҗаты турында белемнәрен киңәйтү, шигырьләренең асылына төшенү.

2. Укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү.
3. Укучыларда М.Җәлил иҗатына һәм шәхесенә карата ихтирам, милли үзаң, горурлык хисе тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**
**Метапредмет**:
*Коммуникатив универсаль уку гамәлләре*: сыйныфташның фикерен тыңлый белү, уртак фикергә килә алу;
*Танып-белү универсаль уку гамәлләре*: дәреслек, өстәмә материал, видеоматериал белән эшләргә өйрәнү, төп мәгълүматны аерып ала белү, төгәл җавап бирә алу;
*Регулятив уку гамәлләре*: уку мәсьәләсен кабул итә алу, план буенча эш йөртә белү.
**Шәхси** : татар әдәбиятына кызыксыну булдыру;
**Җиһазлау:** М.Җәлил портреты, китап күргәзмәсе, М.Җәлил турында презентация.

**Уен барышы.**

"Җырларым"җыры яңгырый.(М.Җәлил сүзләре, Рөстәм Яхин музыкасы)

I. Укытучының кереш сүзе.

– Хөрмәтле укучылар! 15 февраль – легендар шагыйребез М.Җәлилнең туган көне. Ул - татар халкының сөекле улы, шигырьләре белән фашизмга каршы аяусыз көрәш алып барган шагыйрь. Аның исеме бөтен дөньяга таныш. Менә бүген дә без сезнең белән аның турында сөйләшергә җыелдык. Кичәбез "Тамчы-шоу" ярыш формасында үтәр. Бүгенге кичәбездә 6,7нче сыйныф укучылары катнаша. 1нче команда 6нчы сыйныф укучылары, команданың исеме - "Тапкырлар", 2нче командада - 7нче сыйныфлар, команданың исеме - "Зирәкләр". Укучыларыбызның чыгышларын жюри бәяләп барыр.

II. Беренче тур.

- Ярышыбызны башлыйбыз, беренче тур. Ул “Батыр - берне, белемле меңне егар” дип атала. Тапкырлар командасына беренче сорау. Жюри әгъзалары җавапларны бәяләп барырлар.

**1. Муса Җәлил кайчан һәм кайда туган?**

*Көтелгән җавап: Муса Мостафа улы Җәлилов 1906 нчы елның 15 нче февралендә Оренбург өлкәсе Шарлык районы Мостафа авылында туа.*

**2. М.Җәлил нинди мәдрәсәдә укый?** *Көтелгән җавап: Хөсәения.*

**3. 1922 елда Җәлил кайсы шәһәргә килә?** *Көтелгән җавап: Казан.*

**4. Ул Казанда кайда укый?** *Көтелгән җавап: Пединститутның рабфагына укырга керә.*

**5. Ничәнче елларда Мәскәү шәһәрендә белем ала?** *Көтелгән җавап: 1927-1931.*

**6. Беренче шигыренең исеме? (***Бәхет)*

**7. Сугышка кадәр ул кайларда һәм кем булып эшләгән?** *Көтелгән җавап: Муса Җәлил 13 яшендә үк үзенең авылында культура-агарту эшләре алып бара, Казанда газетада эшли, Оренбургта комсомол эшләрендә катнаша, Мәскәүдә ”Кечкенә иптәшләр”, “Октябрь баласы” дигән журналларның мөхәррире була. 1939 нчы елда Казанга кайтып театрда эшли һәм шул елны ТАССР Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе итеп билгеләнә.*

**8. Муса Җәлил ничәнче елда сугышка китә?** *Көтелгән җавап: М.Җәлил 1942 нче елның февралендә Төньяк Көнбатыш фронтка җибәрелә.*

**9. Муса Җәлилнең кайчан һәм ничек гомере өзелә?** *Көтелгән җавап: 1944 нче елның февралендә Җәлил һәм җәлилчеләргә суд була. Суд аларны “дәүләткә каршы җимерү эше” алып баруда гаепле һәм үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның августында Плетцензее төрмәсендә унбер җәлилченең гомере өзелә.*

**10. Муса Җәлилгә нинди мактаулы исем бирелә?**

**11. Шагыйрьнең әсирлектә иҗат ителгән шигырьләре туган илгә ничек кайталар?**

**12. М.Җәлил исемен йөртүче театр ничек атала?** *(Татар дәүләт опера һәм балет театры)*

III. Икенче тур.

- Беренче турга жюри нәтиҗә ясаган арада Муса Җәлил турындагы фильмнан өзек карап алыйк. Игътибар белән карагыз, чөнки алдагы турыбыз видеофильм белән бәйле булачак. Кайсы команда тизрәк җавап бирер.

***1. Әсирлектә М.Җәлил нинди фамилия астында йөри?***

***2. Мообит дәфтәрләре өчен М.Җәлил нинди премиягә лаек була?***

- Сүзне жюрига бирәбез, 2нче турга нәтиҗә ясыйк.

IV. Өченче тур.

- 3 турга килеп җиттек. Бу тур “Шагыйрь иҗатын беләсезме?” дип атала. Укучылар, сезнен алдыгызда карточкалар бар. Анда Җәлил әсәрләреннән өзекләр бирелгән. Ләкин кайбер сүзләр төшеп калган. Сезнең бурыч - шул сүзләрне табу һәм шигырьне сәнгатьле итеп уку. Шигырьләрнең исемен дә әйтергә кирәк булачак.

Бакчачы.

Бик уңган безнең..... (*бакчачы*) бабай,
Яше үзенең...(*туксанда*) бугай.

Ул кояш белән бергә кузгала,
Күрәген ала,... (*җиңен)* сызгана.

Түтәлләр казый,...( *гөлләр*) утырта.
Алмагачларның башларын кырка.

Түтәлне тутырып үсә... (*җиләкләр*),
Нәркис, миләүшә, сөмбел һәм...( *мәкләр)*.

Имән

Юл чатында... (*ялгыз)* гына
Үсеп утыра бер...( *карт)* имән.
Тирә-ягы яшел чирәм,
Ботаклары җиргә тигән.
Таң...( *җилләре*) җилфер-җилфер
Җилфердәтә яфракларын.
Имән...( *җырлый*), искә төшереп,
Шаулап үткән яшь чакларын.
Мең ел элеккемдермонда
Җир... (*казыган*), тир тамызган.
Һәм... (*беренче )* кат имәннең
Яшәү иртәсен кабызган.

- Сезнен эшләрегезне жюрига тапшырабыз, алар бәя бирерләр. Жюри нәтиҗә ясый торсын. Ә без Ибрагимова Азалия башкаруында “Карак песи” җырын тыңлап китик әле.

V. Дүртенче тур.

- Шагыйрьнең иҗаты турында сөйләшүне дәвам итәбез. Сезнең игътибарыгызга - лото. Саннар астында рәсемнәр яшеренгән, саннарны атап, рәсемне ачасыз, бу рәсемнәр М.Җәлилнең кайсы әсәреннән икәнен әйтергә тиеш буласыз. (*“Куян”, “Карак песи”, “Имән”,”Күке”, “Сәгать”, “Кызыл ромашка”, “Чишмә”,”Бүреләр”.)*




- Жюри 4 турга нәтиҗә ясаганда М.Җәлилнең Ф. Җиһанша башкаруындагы “Ышанма” шигырен тыңлап китик.
- Жюрига сүз бирәбез.

VI. Бишенче тур.

- Алдагы турыбыз “Башваткыч” дип атала. Бу турда без кроссворд чишәрбез. Кайсы команда тизрәк һәм дөрес итеп эшне башкарыр? Дөрес чишсәгез, кызыл шакмаклар эчендә сүз килеп чыгачак.

**Башватвыч**

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 10 | | | | | | |
| | | | | Җ | | | | | | |
| | | 1 | З | Ә | Й | Н | Ә | П | | |
| | | 2 | А | Л | И | Ш | | | | |
| | | | 3 | И | Б | Р | А | Һ | И | М |
| 4 | Ж | Ы | Р | Л | А | Р | Ы | М | | |
| | | | 5 | Ч | У | Л | П | А | Н | |
| 6 | Б | Ү | Р | Е | Л | Ә | Р | | | |
| | | 7 | А | Л | Ь | Б | Е | Р | Т | |
| | | | 8 | Ә | М | И | Н | Ә | | |
| | | | 9 | Р | Ә | Х | И | М | Ә | |

1. М.Җәлилнең сеңлесенең исеме ничек? (*Зәйнәп*)
2. Балалар язучысы, Җәлилнең көрәштәше *( А.Алиш*)
3. Абыйсының исеме ничек? **(** *Ибраһим)*
4. ....., шытып сез йөрәгемдә ( *җырларым*)
5. Кызының исеме ничек?( *Чулпан*)
6. Төн буе улашып якында,
   Иснәнеп йөриләр.... ( *бүреләр*)
7.Улының исеме ничек?(*Альберт)*
8.Хатынының исеме ничек? ( *Әминә*)
9.Әнисенең исеме ничек?*( Рәхимә*)

- Нинди сүз килеп чыкты? (*Җәлилчеләр*)
- Җәлилчеләр соңгы сулышларына кадәр илебез азатлыгы өчен көрәшәләр. Алар - кыю солдатлар. Әхмәтҗанова Альбина солдатлар турында җыр башкара.

VII. - Ярышыбызның алдагы туры капитаннар өчен. Алар мәкальне дәвам итәргә тиеш.

**Капитаннар бәйгесе.**

Батыр бер үләр, (*куркак мең үләр*)
Үзем өчен туганмын (*илем өчен үләрмен*)
Батыр яуда (*беленер*)
Батырлыкта – (*матурлык*)
Батырга (*үлем юк*)

Ил яхшылыкны (*онытмас*)
Ватанга хезмәт – (*үзеңә хезмәт*)
Бердә түгел, (*илдә көч*)
Ил иргә, (*ир илгә таяна*)
Илсез кеше – (*телсез сандугач*)

- Бу мәкальләр туган ил, батырлык турында. Батырлык сүзен ничек аңлыйсыз?

VIII. Алдагы эшебез дә Батырлык сүзе бәйле. Бу сүз экранга язылган. Батырлык сүзеннән кем күбрәк сүз төзер икән? Уенның шарты: бары тик исем сүз төркемен белдергән сүзләр генә уйларга кирәк. Чираты җиткәч, кайсы команда сүз таба алмый, шул җиңелгән була.

IX. Йомгаклау.

- Бүгенге уеныбыз ахырына якынлашты.
- Нәтиҗә ясар өчен сүзне жюрига бирәбез.

- Укучылар, М.Җәлилнең мирасы бәяләп бетергесез. Бу шигырьләр сезне һәрвакыт батыр һәм кыю булырга рухландырсыннар.Туган илне яратучылар булып үсегез. Кичәбезне М.Җәлил турында “Бөек шагыйрь – Муса Җәлил” дигән җыр белән тәмамлыйк. Кушылып бергә җырлыйк.

## Дәрестән тыш эшнең проекты

*Галкина Татьяна Геннадий кызы,*
*Казан шәһәре Яңа Савин районы 13 нче татар гимназиясенең башлангыч сыйныф укытучысы*

**Төркем**: 1 нче татар сыйныф укучылары.
**Тема:** Сертотмас үрдәк аппликациясе.
**Дәрестән тыш эшнең формасы**: иҗади остаханә.
**Дәрестән тыш эшнең юнәлеше:** гомуми интеллектуаль.
**Дәрестән тыш эшкә максатлар**: укучыларның сорауларга тулы, дөрес җавап бирүләрен һәм уйлау, фикерләү сәләтләрен үстерү өстендә эшләү.
Укучыларда туган якка карата кызыксыну һәм мәхәббәт уяту.
**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**
**Шәхескә кагылышлы**: кошларны ярату һәм алар турында кайгырту, әхлакый сыйфатларның әһәмиятен аңлау, шәхси карар кабул итә белү.
**Метапредмет:**
*Танып белү УУГ*: эшнең асылын ачыклау һәм үз алдыңа максат кую, эшне җаваплы, аңлап башкару.
*Регулятив УУГ*: күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу,эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.
*Коммуникатив УУГ*: сыйныфташлар һәм укытучы белән эшне оештыруда хезмәттәшлек итү.
**Предметара бәйләнеш**: музыка, рәсем сәнгате.
**Эшне оештыру**: индивидуаль, парларда.
**Эшчәнлек төрләре**: иҗади эшчәнлек, уен эшчәнлеге.
**Чыганаклар**: слайдлар күрсәтү өчен проектор, экран, ноутбук, төсле кәгазь битләре, рәсемнәр,клей,кайчы.
**Дәрестән тыш эшнең план-конспекты:**

1. **Оештыру, мотивлаштыру этабы**

**Укытучы:** Хәерле иртә, укучылар!
**Укучылар:** Хәерле иртә! Балалар, мин сезгә бер әкият укып китәм. Сез бу әкиятнең исемен әйтеп бирә алырсызмы?
Укытучы әкиятне балаларга укый.

**Укучылар:** “Сертомас үрдәк”әкияте.
**Укытучы:** Әйе, укучылар. Эшне парлап оештырсак, җайлырак булыр дип уйлыйм. Сез минем белән килешәсезме?
**Укучылар:** Әйе.

2. **Төп эшчәнлек этабы**

**Укытучы:** Тактада төсле кәгазьләр эленеп тора (сары,кара,кызыл төсләр).
Кызыл төстәге кәгазьдән томшыгын һәм тәпиләрен, кара төстәге кәгазьдән күзен һәм канатын шаблон ярдәмендә кисәчәкбез. Һәр партада кызыл, сары, кара төсле кәгазьләр бар. Без сезнең белән үткән дәрестән тыш чарада бу эшне башлап җибәргән идек инде. Сары төстәге кәгазьдән үрдәкнең гәүдәсен кискән идек. Һәр партада сары үрдәк шаблоны бар. Хәзер, парларга бүленеп, үрдәкнең күзен, томшыгын, тәпиләрен һәм канатын кисеп ябыштырабыз. Эшебезне башлыйбыз.

Балалар парларда эшлиләр. Бер бала кара төстәге кәгазьдән шаблон ярдәмендә күзен һәм канатын кисә, икенче бала кызыл төстәге кәгазьдән шаблон ярдәмендә тәпиләрен һәм томшыгын кисә.

**Укытучы:** Кайчы белән сак эшләгез, бер–беребезгә кайчыны сабы белән бирегез.
Килеп чыккан шаблоннарны үрдәккә ябыштырыгыз.
Нәтиҗәдә һәр пар үзенең үрдәген тәкъдим итә.
**Укытучы:** Балалар, сез үрдәк турында нинди әкиятләр, җырлар, табышмаклар беләсез?
**Укучы:** “Сертотмас үрдәк” әкиятен беләбез.
**Укучы:** “Чума үрдәк, чума каз” дигән җырны беләбез.
**Укытучы:** Әйдәгез әле, балалар, шул җырны җырлап, бераз ял итеп алыйк. (*Ял вакыты, зарядка*)
**Укучылар**: “Чума үрдәк,чума каз “ дигән җырлы уен уйныйлар. Бер-берсен уенга чакыралар.
**Укытучы:** Дәрестән тыш чараны дәвам итәбез. Әзер үрдәкләрегезгә карагыз әле.Тагын нәрсәләр өстәп була? Экрандагы эталонга карыйк әле.
Балалар экрандагы эталон буенча эшләрен чагыштыралар.
**Укучылар**: Үрдәкләр барысы да сары төстә.
**Укучы:** Бер үрдәктә бантик бар.
**Укытучы:** Балалар, сез үзегезнең үрдәкләрегезгә бантик ясап куя аласызмы?
**Укучылар:** Әйе, кызыл төстән башына, ә кара төстән муенына бантик ясап куя алабыз.
**Укытучы:** Инде соңгы үрдәкне карыйбыз,бу үрдәкнең башында эшләпә. Сез шулай ук үрдәккә эшләпә дә ясап куя аласыз.
Балалар үрдәкнең муенына кара төстән бантик, ә башына кызыл төстән эшләпә кисеп ябыштыралар.

3. **Рефлексия.**

**Укытучы:** Һәр пар үзенең үрдәген күрсәтә.

**Укытучы:** Без бу үрдәк шаблоннарын нинди дәресләрдә куллана алабыз?

**Укучылар:** Рәсем дәресендә, математика дәресендә.

**Укытучы:** Әйе, балалар, рәсем дәресендә без бу шаблон белән төрле рәсемнәр ясый алабыз.Ә математика дәресендә мәсьәләләр чишкәндә куллана алабыз.

Шуның белән безнең дәрестән тыш чарабыз тәмам. Сау булыгыз!

## Дәрестән тыш эшнең проекты

*Ибраһимова Эльмира Муса кызы,*
*Казан шәһәре Яңа Савин районы 13 нче татар гимназиясенең*
*башлангыч сыйныф укытучысы*

**Төркем:** 3 нче сыйныф укучылары.

**Тема:** Татарстан минем туган ягым.

**Дәрестән тыш эшнең формасы:** иҗади остаханә.

**Дәрестән тыш эшнең юнәлеше:** гомуми интеллектуаль.

**Дәрестән тыш эшкә максатлар:**

**Эшчәнлек буенча:** предметка карата таныш белү һәм эмоцианаль кызыксыну уяту; эш гамәлләренә күнекмәләрне камилләштерү: лэтбук ясау рәсемнәр белән эшләү, иҗади мөмкинлекләрне камилләштерү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***<u>Шәхескә кагылышлы:</u>*** укуга һәм танып белүгә мотивация формалаштыру; туган якка ихтирам булдыру уңаеннан укучыларның гомуми үсешенә уңай мөнәсәбәт булдыру.

***<u>Метапредмет:</u>***

*<u>Танып белү УУГ</u>*: уку мәсьәләсен кабул итү һәм дәрес (чара) дәвамында шуның буенча эшләү; телдән сөйләмдә үз фикерләреңне формалаштыра белү; тиешле мәгълүматны табу һәм аерып алу; өлешләрдән бербөтенне төзи белү; гомумиләштерү.

*<u>Регулятив УУГ</u>*: куелган мәсьәләне чишүдә алгоритмны куллана белү һәм үз эшчәнлегеңне планлаштыру, контрольгә алу; барлыкка килгән ситуациядә ориентлаша белү; үзеңнең һәм башкаларның фикерен дөрес бәяләү; башкарылган эшнең сыйфатын билгеләү.

*<u>Коммуникатив УУГ</u>*: хезмәттәшлектә башкаларның фикерләрен исәптә тоту һәм карашыңны яклый белү; сөйләмнең диалогик формасы белән эш итә белү; үз фикереңне һәм карашыңны формалаштыру; бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү.

**Предметара бәйләнеш:** әдәбият, әйләнә-тирә.

**Эшне оештыру:** фронталь, индивидуаль, парларда.

**Эшчәнлек төрләре**: танып белү эшчәнлеге, иҗади эшчәнлек,
**Чыганаклар:** слайдлар күрсәтү өчен проектор, экран, ноутбук, лэтбук китапчыгы өчен биремле кәгазь битләре, рәсемнәр, табышмаклар.
**Дәрестән тыш эшнең план-конспекты:**

***I. Оештыру, мотивлаштыру этабы***

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.
*Укытучы*: Хәерле иртә, укучылар! Кәефләрегез әйбәтме?
Әйдәгез әле, бер-беребезгә карап, елмаеп, яңа көн белән котлыйк.
*Укучылар:* Хәерле иртә, миңа!
- Хәерле иртә, сиңа!
- Хәерле иртә,сезгә!
- Хәерле иртә, миңа!
- Утырыгыз. Укучылар сез дәрескә (чарага) әзерме?
- Әзер.

*Укытучы:* Әйдәгез,укучылар,тактага карыйк әле.Бу нәрсә?
*Укучылар:* Бу карта. *(Слайдта Татарстан картасы ачыла.)*
*Укытучы:* Бу нәрсә картасы?
*Укучылар:*Татарстан картасы?
*Укытучы*: Картада нинди сүзләр язылган? Укып китик әле. *(Слайд. Картада шәһәр исемнәре ачыла.)*
*Укучылар:* Казан, Яр Чаллы, Яшел Үзән, Әлмәт. Бу шәһәр исемнәре. *(Слайд. Шәһәр исемнәре ачыла.)*
*Укучылар:* Кырлай, Әлдермеш, Кече Кирмән, Наратлы, Яуширмә. Бу авыл исемнәре. *(Слайд. Авыл исемнәре ачыла.)*
*Укучылар:* Идел, Казансу, Чулман, Нократ. Бу елга исемнәре. *(Елга исемнәре ачыла.)*
*Укытучы:*Укучылар болар нәрсәләр? *(Слайд. Хайван рәсемнәре чыга.)*
*Укучылар:*Болар хайваннар. Аю, төлке, куян, бүре.
*Укытучы*: Бик яхшы укучылар.
*Укытучы:* Ә хәзер игътибар белән бер җыр тыңлап китик әле.
Җыр нәрсә турында. *(С.Фәтхетдинов башкаруында "Мин яратам сине Татарстан" җырын тыңлау һәм җырлау)*
*Укучылар:* Татарстан турында.
*Укытучы:* Әйе, укучылар бу Татарстан сүзе.
*Укучылар:* Димәк, без бүген Татарстан турында, аның табигате турындагы текст белән эшләрбез. "Татарстан минем туган ягым"дигән лэтбук китапчыгы ясарбыз. Быел без Татарстан АССР оешуның 100 еллыгын билгеләп үтәбез.

***II. Төп эшчәнлек этабы.***

*Укытучы:* Укучылар сезнең алларыгызда ак кәгазьләр бар. Шулардан мин күрсәткәнчә китапчыклар ясагыз.*( Укучылар кәгазьне бөкләп китапчык ясыйлар.)*

Без бүгенге дәрес (чара) дәвамында шушы китапчыкның эчтәлеген тутырырбыз. Ә хәзер алдыгызда яткан "Пазллар" дип язылган конверттан пазлларны алып Татарстанның картасын төзегез һәм китапчыкка ябыштырыгыз. (*Укучылар биремне башкаралар)*

*Укытучы:* Әйдәгез, татарча сөйләшеп алыйк, әле. Тактада бирелгән сүзләрне кулланып җөмләләр төзеп китик (Слайд. *Ярдәмче сүзләр ачыла. Казанда, Татарстанда, Г.Тукай урамында, М. Җәлил урамында, Адоратский урамында.*)

*Укучылар:* Мин.... яшим.

*Укучылар:* Без.... яшибез.

*Укытучы:* Ә хәзер карандаш формасындагы шаблоннарга шушы җөмләләрне язып, лэтбукка ябыштырып куегыз. (*Укучылар биремне башкаралар.*)

*Укытучы:* Укучылар без кайда яшибез?

*Укучылар:* Без Татарстанда яшибез. (*Слайдта Татарстан турында текст ачыла.*)

Укытучы: Әйдәгез шушы тестны укып үтик әле. (*Бер укучы такта янына чыгып текстны укый.)*

*Укытучы:* Укучылар хәзер безгә таныш булмаган сүзләрне карап үтик, әле.

(Тактада сүзләр: бай-богатый; җитез-прыткий, ловкий быстрый; усал - злой; көчле - сильный; поши - лось)

*Укытучы:* Ә хәзер шушы сүзләрне ике төрле шаблонга бүлеп языгыз. Нәрсә? шаблонына һәм Кем? шаблонына. *(Укучылар биремне үтиләр. Парларда эшләрне тикшерү.)*

*Укытучы:* Укучылар текстны тәрҗемә итеп үтик әле. *(Тестны тәрҗемә итү.)*

Физкультминутка.

*Укытучы:* Балалар, әйдәгез,сез дә диалог төзеп карагыз,әле. (*Парларда эш.)*

-Син кайда яши**сең** ?

- Мин... яши**м**.

- Ә син... яши**сең** ?

- Мин... яши**м**.

*(Диалогны такта янында сөйләү.)*

*Укытучы*: Укучылар "Табышмаклар" дип язылган конверттан табышмакларны алып, укып җавапларын табарга кирәк. Аннары "Хайваннар" дигән конверттан шул хайван рәсемнәрен табып лэтбукка ябыштырыгыз. *(Укучылар иҗади биремне башкаралар.)*

*Укытучы:* Укучылар мин сезгә бүгенге текстка кагылышлы берешәр җөмлә таратам. Җөмләләре дөрес булган укучылар "Дөрес" дип язылган почмакка, ә

җөмләләре дөрес булмаган укучылар “Дөрес түгел” дигән почмакка җыеласыз. *(Укучылар биремне үтиләр.)*

*Укытучы:* Ә без эшебезнең йомгаклау өлешенә килеп җиттек, укучылар. Хәзер сез һәрберегез лэтбукта булган информацияне һәм текста булган мәгълүматны файдаланып, Татарстан турында телдән хикәя төзегез әле. (*Лэтбук буенча төзегән хикәяләрен сөйләү. Нәтиҗә ясау, бер-берсен бәяләү.)*

**Рефлексия.**

*Укытучы:* Дәрестән тыш эшебез ахырына якынлаша, укучылар. Бүгенге эшебез сезгә ошадымы?

*Укучылар:* Әйе.

*Укучылар:* Мин булдырдым. Мин үз-үзем белән канәгать.Мин яхшырак та булдыра ала идем. (*Үзләрен бәялиләр.)*

Син булдырдың. Мин синең белән канәгать. Син яхшырак та булдыра ала идең.*(Иптәшләрен бәялиләр)*

Укытучы: Рәхмәт, укучылар. Дәрестән тыш эшебез тәмам. Сау булыгыз!

## Шәвәли бездә кунакта
## (5 нче сыйныфта дәрестән тыш чара)

*Садриева Халидә Габделәхәт кызы,*
*Казан шәһәре Яңа Савин районы 13 нче татар гимназиясенең*
*туган тел (татар теле) һәм әдәбияты укытучысы*

***Дәрестән тыш чараның формасы:*** әдәби-музыкаль кунакханә

***Дәрестән тыш чараның юнәлеше:*** гомуми интеллектуаль

***Дәрестән тыш чарага максатлар:***

- укучыларда Ш. Галиев иҗатына кызыксыну уяту,
- сәнгатьле сөйләм күнекмәсен камилләштерү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***<u>Шәхескә кагылышлы</u>:*** әхлакый сыйфатларның әһәмиятен аңлау.

***<u>Метапредмет:</u>***

*<u>Танып белү УУГ</u>*: эшнең асылын ачыклау һәм үз алдыңа максат кую, эшне җаваплы, аңлап башкару.

*<u>Регулятив УУГ</u>*: күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу, эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

*<u>Коммуникатив УУГ</u>*: сыйныфташлар һәм укытучы белән эшне оештыруда хезмәттәшлек итү; эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыра алу; коммуникатив максатлардан чыгып, сүзләрне дөрес һәм урынлы куллану.

***Эшне оештыру:*** фронталь, индивидуаль.

***Эшчәнлек төрләре***: әдәби-иҗади эшчәнлек, танып белү эшчәнлеге, уен эшчәнлеге.

**Дәрестән тыш чараның барышы:**

1. ***Оештыру, мотивлаштыру этабы***

*Укытучы:* Хәерле көн, укучылар!

*Укучылар:* Хәерле көн!

*Укытучы:* Хәлләрегез ничек?

*Укучылар:* Яхшы, рәхмәт!

*Укытучы:* Һәр баланы җайлый,

Һәркем аны таный.

Шигъри теле һаман

Былбыл булып сайрый.

Балалар, әлеге шигъри юллар кем турында икән?

*Укучылар:* Бу юллар балалар һәм өлкәннәрнең яраткан шагыйре Шәүкәт ага Галиев турында.

2. ***Төп эшчәнлек этабы***

*Укытучы:* Беренче чиратта, Шәүкәт Галиев балалар әдәбиятында шаян шигырьләре белән танылa. Ул, тормышның кызыклы якларын табып, балалар белан бүлешә, аларны рәхәтләнеп көлдерә, яхшыны — начардан, затлыны - затсыздан аерып күрсәтә. 1962 елда аның махсус балаларга атап язган шигырьләре тупланган «Камырша» исемле беренче җыентыгы басылып чыга.

*(Ишек шакыйлар.)*

*Укытучы:* Безнең чарага кемдер килгән ахры. Кем бар анда?! Керегез, рәхим итегез! *(Сикергәләп, Шәвәли килеп керә)*

*Шәвәли:* Мин — Шәвәли,

Шук малай,

Үткен малай,

Ут малай!

Мин бик уңган,

Өлгер мин,

Юк-бар белән

Көлдермим!

Бик тапкыр мин,

Җыйнак мин,

Мин, мин бик,

Тыйнак мин!

*Укытучы:* Балалар, кунакны таныдыгызмы?

*Укучылар*: Әйе, бу Шаүкәт аганың Шәвәлие.

*Укытучы*: Әйдә, Шәвәли, рәхим ит! Без бүген синең турыда сөйләшербез дип тора идек.
*Шәвәли:* Менә шулай бик сизгер инде мин, кайда минем турында сүз булса, киләм дә җитәм. Бүген дә менә сезнең янга киләсем, чарагызда катнашасым килде.
*Укытучы*: Килеп дөрес эшләгәнсең, Шәвәли дус. Без сиңа бик шат. Шулаймы, балалар? *(Әйе!)*
*Укытучы*: Укучылар, Шәвәли турында нәрсәләр беләсез соң?
*Укучылар*: Шәвәли — Шәүкәт абый Галиев герое. Ул шук, үткен, шаян, өлгер, җитез, җыйнак, тыйнак.
*Укучылар:* Шәвәли — кызыксынучан һәм эзләнүчән малай.
*Шәвәли*: Әйе, Шәүкәт абый мине дөньяга чыгарды, балаларга танытты.
*Укучылар*: Шәвәли дус, ә синең кулыңда нинди китап ул?
*Шәвәли*: Ә-ә, күреп торам, биредә китап укырга яраткан, куп белергә теләгән балалар җыелган икән! Мин «Шәвәли китабы» алып килдем. Әлеге китапны укыганыгыз бармы? (Бар!)
*Укытучы*: Шәүкәт Галиевның Шәвәлие бөтен тирә-якка танылган. Мәскәү нәшриятында чыккан «Кто играет на курае?» китабы рус телле балаларны да Шәвәли белән таныштыра.
*Шәвәли:* Балалар, минем турыдагы шигырьләрне ничек беләсез икән, тикшереп карыйм әле үзегезне:
— Иң шатлыклы көнемдә мине кибеткә ни өчен җибәрделер? (*Камыр алырга җибәрделәр.)*
— Бервакыт мин бик кызыккан әйберне алып, аны тотып бетердем дә, өйгә кайтырга куркып йөрдем. Шуннан сон миңа нинди кушамат тактылар? (*Ислемай.*)
— Кемне тынычландырганда мин сөйләшергә тәкъдим иттем? (*Энеңне.*)
— Әни мине әбиләргә нинди йомыш белән җибәрде? (*Коймак илтергә.*)
— Мин нәрсәне этеп-төртеп савыт эченә керттем? (*Камырны.*)
— Сарык йонын ала торган урынны мин ничек атадым? *(Сарыкмахерская.)*
— Нишләгәч мина җир шары бәрелде? (*Таеп егылгач.)*
*Шәвәли*: Афәрин, дусларым. Минем турыдагы шигырьләрне шәп беләсез икән.
Укытучы. Шәвәли дус, безнең балалар Шәүкәт абыйларының күп кенә шигырьләрен яттан беләләр. Әйдәгез, укучылар, үзегез өйрәнгән шигырьләрне яттан сөйләп күрсәтегез әле.

*(Укучылар Ш.Галиевның кызыклы шигырьләрен яттан сөйлиләр. Шәвәли дә тик тормый: үзе турында шигырь туры килсә, кызыклы сүзләр әйтеп куя.)*

*Укучылар:* Шәвәли дус, без әле рәсем ясарга да яратабыз. Сиңа Шәүкәт абыйның әсәрләренә карата ясаган ресемнеребезне тәкъдим итәбез.
*Укытучы:* Яле, Шәвәли, кайсы шигырьләрдән икәнен танырсыңмы?

*(Шәвәли укучыларның рәсемнәрен карый, кайсы шигырьгә карата ясалганын әйтеп бирә.)*

*Укытучы:* Балалар, әйдәгез әле без сезнең белән хәзер бераз ял итеп алыйк. Шәвәли дә инде арыгандыр. Шулаймы Шәвәли?

*Шәвәли:* Ярый шул. Минем дә балалар белән бераз хәрәкәтләнеп аласым килә.

*Укытучы:* Балалар, без сезнең белән Шәүкәт аганың көйгә салынган шигырьләрен җыр итеп тә өйрәнгән идек. Фәнис Якупов көйгә салган «Бииләр итек, читекләр» җырын башкарыйк әле.

*(укучылар «Бииләр итек, читекләр» җырын җырлыйлар һәм бииләр)*

*Укытучы:* Укучылар, Шәүкәт абый үзенең шигырьләрендә балаларда гел яхшы сыйфатлар гына тәрбияләргә омтылган: чисталык, пөхтәлек, тырышлык, сабырлык, өлкәннәргә хөрмәт, табигатебезгә сакчыл караш, начар гадәтләрдән көлү — аның әсәрләрендә ачык чагыла.

*Шәвәли:* Балалар, минем сезнең тапкырлыгыгызны да сынап карыйсым килә. Мин сезгә Шәүкәт аганың шигырьләреннән өзекләр укыйм, ә сез шигырьнең исемен әйтерсез.

(*Шәвәли шагыйрьнең әсәрләреннән өзекләр укый.)*

*Шәвәли:* Афәрин, балалар! Сез миңа бик ошадыгыз. Сезнең белән бик күңелле булса да, хәзер миңа китәргә вакыт.

*Укучылар*: Безнең чарабызда катнашканың өчен без синең үзеңә дә бик рәхмәтле, Шәвәли дус.

***3. Рефлексия***

*Укытучы:* Дәрестән тыш чарабыз ахырына якынлаша, укучылар. Сезгә ошадымы ул?

*Укучылар:* Әйе.

*Укытучы:* Шәвәлидән үрнәк алырга буламы?

*Укучылар:* Әйе, Шәвәли акыллы, тапкыр, шаян малай. Аңарда үрнәк алырлык сыйфатлар бар.

*Укучылар:* Шәвәли чиста-пөхтә, уңган, тәрбияле малай.

*Укытучы:* Рәхмәт, укучылар. Дәрестән тыш чарабыз тәмам. Сау булыгыз!

## Тема: Куәтле бит ул безнең ил!

*Гыйләҗева Эльвира Зөфәр кызы*

*Казан шәһәре Мәскәү районы КФУ каршындагы 2 нче татар гимназиясе беренче квалификацияле математика һәм информатика укытучысы*

**Юнәлеше:** гомуми интеллектуаль.

**Төре:** танып белү.

**Класс**: 2 нче класс.

**Үткәрү формасы**: түгәрәк.
**Предметара бәйләнеш**: математика һәм робототехника.
**Эшне оештыру**: төркемдә, парларда, индивидуаль эш.
**Максат**:

дидактик: математика алымнарын кулланып роботны төзү;

үстереш: әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, ишетә белү, мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру;

тәрбияви: төркемнәрдә дустанә аралашып эшләү культурасын үстерү, Ватанны ярату хисләре тәрбияләү.

**Бурычлар**:

1. Логик фикерләү сәләтләрен үстерү.
2. Бирелгән рәсем буенча төркем белән роботны төзү
3. Тел байлыкларын арттыру, камил әдәби телдә сөйләшү.
4. Һәр укучыны иҗадый характердагы актив танып-белү эшчәнлегенә тарту.
5. Программа һәм алгоритм төзергә өйрәнү.

**Планлаштырган нәтиҗәләр**:

1. Төркемнәрнең дус, бердәм эшчәнлеге.
2. Математик төшенчәләрне аңлаткан алгоритмнар уйлап табу

**Җиһазлау**: ноутбук, интерактив такта, проектор, презентация, конструктор лего
**Кулланылган әдәбият**: “Мәгариф” журналлары, “Ачык дәрес” газеталары.

**Дәрестән тыш эшчәнлекнең барышы:**

I. Оештыру өлеше.

Укытучы:

Исәнмесез, укучылар!
Килдегезме дәрескә?
Уен, көлке, эшләрегез
Калдымы тәнәфестә?

II. Актуальләштерү.

1. Әңгәмә формасында

Укытучы:

- Балалар ничек уйлыйсыз, илләргә ни өчен армия кирәк?

(*Укучыларны фикерләре әйтелә*)

Укытучы:

- Сугыш вакытында солдатларны саклар өчен нинди җиһазлар, техника кулланыла?
- Төрле шартлаткычлар, мылтыклар, танклар һ.б.

- Дөрес, укучылар, бик әйбәт! Бүген без тиздән Ватанны саклаучылар көне уңаеннан без шул техникаларның берсен ясыйбыз. Хәзер игътибарны экранга юнәлтик. Нәрсә күрәсез сез экранда?

1 нче рәсем




- Саклаучы танк.

2 нче рәсем

(*Беренче танк рәсеме*)




3 нче рәсем

(*Төрле илләрдәге элеккеге танклар рәсеме*)




Укытучы балалардан һәрбер танкның исемнәрен сорап чыга.

2. Әңгәмә

- Балалар ничек уйлыйсыз тигез җирдә танкның тизлеге күпме?

(*Төрле фикерләр әйтелә*)

Укытучы:

- Уртача 54 км/сәг. кә җитә. Ә тотрыклы, чокырларда тизлеге күпме?

- Уртача 28 км/ сәг.

4 нче рәсем

(*Танкның төзелеше*)




Укытучы рәсемнән күрсәтә:

- Өстә һәм аста корпус маңгае, корпус борты, корпус койрыгы, төбе, корпус түбәсе, башня маңгае, туп төре сырлы көпшә, тәгәрмәчле чылбыр (гусеницы)

3. Роботны төзү өстендә эш.

(*Һәрбер бала каршысында ноутбук һәм лего конструкторы тора. Ноутбук көйләнелгән, программа ачык була, бала шул рәсемнәргә карап ясый*).

5 нче рәсем




Балалар роботны төзиләр, эш барышында укытучы ярдәм кирәк булган балаларга булыша.

Әңгәмә.

- Сез математиклар микән, тикшереп карыйк әле. Сезнең белән бер уен уйныйбыз.

“Так сан, җөп сан” уены. Так сан булса тыпырдыйбыз, җөп сан булса чәбәклибез. (*Төзегән вакытта уен уйналына*)

- Балалар, сез бик акыллы, ярдәмчел, тырыш, оста.

Роботлар төзелеп беткәч, программа төзиләр.




- Балалар, моторны 1 м/с тизлеге белән җибәрәбез, 1 секунд көтеп торабыз, моторны 3 м/с тизлеге белән җибәрәбез, 1 секунд көтеп торабыз шуннан сон моторны 5 м/с тизлеге белән эшләтәбез.
- Бик яхшы.




Балалар программаны WeDo 2.0 да эшлиләр.
2 нче күнегүне эшлиләр.




Э аннан сон 3 нче күнегүне.




Балалар, әйдәгез хәзер роботның тизлеген, вакытын куеп үткән юлын табабыз?

4. Проблеманы чишү юлларын эзләү.

Экранда бирелгән рәсем буенча тизлекне табу.

$$V = \frac{L}{t}$$

V -
L -
t-в

| L, м | t,с | V, м/с |
|---|---|---|
| | | |




- Беренче рәсем буенча нәрсә әйтә аласыз?

Балаларның фикере әйтелә.

- Икенче рәсем буенча ни әйтә алырсыз?

Балаларның фикере әйтелә.

- V - тизлек, L – үткән юл, t – вакыт, тизлекне табар өчен юлны вакытка бүләбез.

Балалар таблицага саннарны куеп формула белән чишәләр.

Шулай ук төрле саннар белән дә эшлиләр.

- Укучылар юлны да, вакытны да табып була. Юлны табар өчен тизлекне вакытка тапкырлыбыз L= V * t, вакытны табар өчен юлны тизлеккә бүләбез: t = L / V

5. Нәтиҗә ясау

- Чара (дәрес) сезгә ошадымы?

Фикерләр ишетелә.

- Хәзер укучылар WeDo 2.0 программасында робот белән фотога төшегез. Ул фотоларыгыз сезнең ел ахрында экраннарга чыгачак. Чара ахрына якынлаша, роботларыгызны сүтә аласыз.

6. Йомгаклау

Укытучының йомгаклау сүзе:

- Бүген өйгә кайтып әти, бабай, абыйларыгыздан кызыксыныгыз әле. Армиядә булганнармы? Кайларда хезмәт иткәннәр? Нинди сугыш кораллары белән эшләгәннәр? Шулар турында миңа да икенче дәрескә сөйләрсез. Ә хәзер балалар, безнең дәресебез тәмам. Бүген бик тырышып эшләдегез. Хезмәтегез өчен зур рәхмәт! Алга таба да акыллы, зирәк укучылар булыгыз! Сау булыгыз!

**Тема: Онытырга хакыбыз юк,**
**Онытырга кушмый Мусалар!**

*Фәсахова Миләүшә Рәүф кызы,*
*Казан шәһәре Совет районы 15 нче урта гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Юнәлеше**: гомуми интеллектуаль.
**Төре**: танып белү.
**Формасы**: кичә.
**Максат:** укучыларны Бөек Ватан сугышында катнашкан әдипләр белән таныштыру, Муса Җәлил турында белемнәрен ныгыту. Алар каһарманлыгы аша укучыларда милләтебез белән горурлану хисе, патриотизм тәрбияләү, тынычлыкның кадерен белергә өйрәтү. Укучыларда җитезлек, бердәмлек сыйфатларын арттыру.
**Шәхескә кагылышлы:** патриотик сыйфатларның әһәмиятен аңлау.
**Метапредмет:**
Танып белү УУГ: эшне җаваплы, аңлап башкару.
Регулятив УУГ: күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп эш башкару.
Коммуникатив УУГ: сыйныфташлар һәм укытучы белән эшне оештыруда хезмәттәшлек итү; эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыра алу.
**Дәрәҗәсе**: мәктәп күләмендә чыгыш ясау.
**Җиһазлау**: ноутбук, проектор, электрон презентация « Онытырга хакыбыз юк, Онытырга кушмый Мусалар!» Аудиоязма («Озатып вокзаллар каршында» җыры, Роберт Әхмәтҗанов сүзләре, Фәтхерахман Әхмәдиев көе. «Минем бабам – миллионнарның берсе» дигән язу.

**Кичәнең барышы:**

- Исәнмесез, укучылар! Хәерле көннәр сезгә. Көн буена җитәрлек яхшы, шәп кәефләр телим барыгызга да. Ә хәзер әйдәгез әле җыр тыңлап үтик.

Озатып вокзаллар каршында
Маңгайдан үптеләр аналар
Тузанлы юллардан үттеләр
Дөньяны күрмәгән балалар

Балалар керделәр утларга,
Балалар сүз бирде тупларга.
Күпләре, төренеп шинельгә,
Калдылар еракта йокларга.

«Балалар, торыгыз, балалар,
Ашыгыз суына табында…»
Ничә ел тормыйлар балалар
Иделдә һәм Дунай ярында…

Уятма, йокласын, син, ана,
Айларны, елларны санап бар:
Күңелдә һаман яшь, гел бала —
Кайтмаган солдатлар, солдатлар

Ана ул йокламый, сабые
Юрганын ачса да уяна.
Аналар йөрәге шикелле
Мәйданда мәңгелек ут яна.

Аналар йөрәге шикелле
Ут яна, уйлана, талпына.
Аналар хәтере шикелле
Җил йөри курганнар артында

Бу җыр «Озатып вокзаллар каршында» дип атала, Роберт Әхмәтҗанов сүзләренә язылган, Фәтхерахман Әхмәдиев көе. (Экранда сугыш белән бәйле слайдлар һәм җыр тексты).

- Җыр тыңлаганда уйлап утырыгыз әле: сүз нәрсә турында бара?
- *(Җыр тыңлаганнан соң, сорау кабатлана.*)
- Бу җырда сүз нәрсә турында бара?
- Әйе, бик дөрес, сугыш турында.
- Укучылар, сугыш белән бәйле нинди ассоциацияләр күз алдыгызга килә? Нинди сүзләр әйтә аласыз? ***Корал, ут, үлем, кан, солдат, күз яшьләре, кайгы, курку, газап, бәхетсезлек, корбан.*** *(Тактага шушы сүзләр язылган карточкалар эленә).*
- Әйе, чыннан да, сугыш кешеләргә кайгы, хәсрәт, күз яшьләре алып килә, балалар. Сез бик дөрес әйттегез.
- Без бүген сугыш турында, Бөек Ватан сугышы турында сөйләшербез һәм очрашуыбызның темасы итеп шушы сүзләрне алыйк:

«Онытырга хакыбыз юк,
Онытырга кушмый Мусалар!»

Укучылар, татар халкында исемнәр бик күп, ә ни өчен соң шагыйрә *Саҗидә Сөләйманова* бу юлларда нәкъ менә Муса исемен атаган? Укучылар, сез ничек уйлыйсыз? (Муса Җәлил)

- Ә кем соң ул Муса Җәлил, аның турында нәрсәләр беләсез?

- Әйе, Җәлил исеме хаклы рәвештә сугыш еллары татар поэзиясе символы булып санала. Күп кенә татар язучылары, кулларына корал алып, Ватанны сакларга күтәрелә. Татарстан Язучылар берлегенә кергән 53 язучының 25-е сугышның беренче елында ук фронтка китә.

- Язучылар, шагыйрьләр генә түгел, ә барлык Татарстан халкы кешеләренең җиңүгә керткән өлеше бик зур була.

- Укучылар, әйтегез әле, без яшәгән ил ничек атала? (Тактада Россия картасы). Ә бит сугыш елларында безнең илебез алай дип аталмаган. Бәлки арагызда белүчеләр бардыр? (Совет Социалистик Республикалар Союзы). Кыскача гына әйтеп китәм: 1991 нче елда СССР дигән зур дәүләт аерым илләргә таркала.

- Балалар, Россия төрле-төрле республикаларны берләштерә бит. Без сезнең белән нинди республикада яшибез?

- Әйе, бик дөрес, Татарстан Республикасында. Ләкин безнең республика да гел шулай аталмаган. Ә ничек аталган икән соң?

- 1920 елда Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы оеша. Ягез, республикабызның шушы атамасын әйтеп карагыз әле. (Кыскартканда, гадәттә, сүзләрнең баш хәрефләре алына, сез бу турыда беләсез инде. Әйдәгез, бу сүзләрне кыскартып карагыз әле. Әйе, ТАССР дип йөртелгән безнең республика. Ә хәзер датага игътибар итегез. ТАССР ничәнче елда оешкан инде? Әйе, 1920 елда.

- Шулай булгач, 2020 елда без Татар Автоном Совет Социалистик Республикасы оешуының ничә еллыгын билгеләп үтәчәкбез? (100 еллыгын).

- Укучылар, тарих өчен 100 ел бик зур сан түгел, ләкин шул 100 ел эчендә халкыбызның тормышы өчен әйтеп бетергесез зур роль уйнаган еллар бар. Шундыйларның иң дәһшәтлесе, иң авыры Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. Дөрес, безнең республикада сугыш бармаган. Ләкин безнең халкыбыз үз-үзен аямыйча, көнне-төнгә ялгап тылда хезмәт иткән, ә батыр уллары сугыш кырында корал тотып көрәшкән. Әлбәттә, безнең язучыларыбыз, шагыйрьләребез иң алдынгы сафларда булган. Алар сугышның эчендә кайнап фронт газеталарында сугышчыларның батырлыгын яктыртып һәм үзләренең патриотик иҗатлары белән Бөек җиңүне якынайтканнар.

- Укучылар, әйтегез әле, сез Бөек Ватан сугышында катнашкан кайсы шагыйрь һәм язучыларны беләсез.

- (Слайд) Әйе, Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим, Гадел Кутуйлар белән бергә әле сез әйтмәгән башка күп әдипләребез явыз дошманга каршы көрәш сафына беренчеләрдән булып басканнар. Изге Җиребез туфрагына аларның да йөрәк каны тамган.

- Бик күп татар әдипләре төрлесе төрле фронтларда сугышып, солдат тормышы, сугыш турында хикәяләр, шигырьләр иҗат иткәннәр.

Укучылар, безнең алдыбызда да сугышчан бурыч тора. Без сезнең белән менә шушы рәсемнәрнең икенче ягына нинди сүзләр язылганын белергә тиеш:

| | |
|---|---|
| Мәңгелек ут рәсеме | Солдат рәсеме |
| Каска, чәчәк рәсеме | Һәйкәл рәсеме |

Бу сугышчан бурычны үтәр өчен бездән белем дә, тизлек тә сорала. Сугыш вакытында да уйлап һәм тиз эшләгәннәр. Әйдәгез, сынатмыйк. 1 кеше балларны санаучы итеп билгеләнә. Уеныбызның шартларын кыскача гына әйтеп китәм: һәр дөрес җавап бирүче командага 1 балл, ә уйлап һәм тиз эшләгәннәргә өстәмә 1 балл бирелә. Өстәлләрегездә шулай ук сигнал картасы күрәсез. Биремне эшләп бетергәннән соң, сигнал картасын күрсәтергә кирәк булачак.

1) Уеныбызны башлыйбыз. Сез сугышта катнашкан бер язучының бер әсәреннән рәсемне дөрес итеп җыярга тиеш буласыз (*әлеге рәсемнәр кискәләнгән була)* һәм артына язылган сүзне укып, командагызның исеме билгелисез.

- Әсәрне һәм авторын дөрес әйткән команда 1 очко ала. Сез әзерме? Башлыйбыз!

А.Алиш “Сертотмас үрдәк”

М.Җәлил “Кызыл ромашка”

А.Алиш “Куян кызы”

А.Алиш “Нечкәбил”

- Нинди командалар барлыкка килде?

4 команда: Кыюлар, Тапкырлар, Батырлар, Уңганнар.

1) Икенче биремгә күчәбез. Рәсемне әйләндерәбез, аның артында «Кем күбрәк белә?» дип язылган.

Бу ярышта Бөек Ватан сугышында катнашкан язучыларны дөрес итеп атасагыз, команда 1 очко ала. Бер әйткәндә бер генә исемне әйтергә ярый. Беренче рәсемнең икенче ягын әйләндерәбез. Анда «Бөек» сүзе язылган.

Киләсе биремгә күчәбез. Бу нәрсә укучылар? «Хат». Укучылар, фронтта хатлар менә шулай өчпочмаклап ясалып килгән. Сез күреп ияләнгән конвертларга салып тормаганнар. Чөнки беренчедән конвертлар булмаган,

икенчедән сугыш вакыты булганга күрә, хатларны тикшергәннәр, өчпочмаклы хатларның эчтәлеген тикшерергә җиңелрәк булган, бу очракта кәгазьгә дә, туганнары өчен язылган кыйммәтле мәгълүматкә дә зыян килмәгән, ачарга да җиңелрәк булган.

- Ә хәзер, укучылар, 1 командадан бер кеше чыга, үзе теләгән хатны ала һәм сез команда белән андагы биремне үтисез. Беренче конверттагы бирем:

- Бирелгән хәрефләрдән әкиятче язучының, Җәлилнең көрәштәшенең, исемен җыегыз.(*Абдулла Алиш.*)

Икенче конверттагы бирем:

- «Минем гомерем моңлы бер җыр иде,

Үлемем дә яңгырар җыр булып», - дигән юлларны язган шагыйрьнең исемен җыегыз! ( *Муса Җәлил.*)

Өченче конверттагы бирем:

- Җәлилнең фронт шигырьләре тупланган китапның исеме ничек? («*Тупчы анты*»).

Дүртенче конверттагы бирем:

- Җәлилнең фашист төрмәсендә язылган шигырьләре нинди китапта басыла? («*Моабит дәфтәрләре»).*

Дөрес җавап биргән командалар 1 очко алалар һәм шулай итеп без сезнең белән икенче рәсемне ачабыз.         Анда «Җиңүгә» дип язылган.

2) Алга таба дәвам итәбез. Өченче рәсемне ачабыз. Анда «Сез - элемтәчеләр» дип язылган.

- Сугыш вакытында элемтәчеләр морзе әлифбасын кулланып хәбәрләшкәннәр. Бу шул вакыт өчен иң кулай һәм популяр элемтә чарасы була. Әйдәгез, сез дә морзе әлифбасын кулланып карагыз әле.

(Һәр командага бирем язылган битләр бирелә).

Анда сүзләр морзе хәрефләре белән язылган. Бөек Ватан сугышында катнашкан милләт исемнәрен кем тизрәк укый: *(Морзе әлифбасы элеп куела.*)

| | | | |
|---|---|---|---|
| - (т) | *-* (р) | - - (м) | - - - * (ч) |
| * - (а) | **- (у) | * - (а) | **- (у) |
| - (т) | *** (с) | *-* (р) | *- - (в) |
| * - (а) | | ** (и) | * - (а) |
| *-* (р) | | | - - - - (ш) |

Беренче укыган команда бер очко ала һәм өченче рәсемнең икенче ягын әйләндерә. Анда «75» дип язылган.

3) Соңгы рәсемне ачабыз. Анда «Минем бабам» дип язылган. Укучылар, әйтегез әле, кайсыгызның бабалары, туганнары сугышта катнашкан? Укучылар сез беләсез инде, 9 май көнне динди акция үткәрелә? (*үлемсез полк*). Бу акциядә катнашканыгыз бармы? Күзләрдән яшь китерә торган бу тантаналы һәм сагышлы чарада мин үзем дә теләп катнашам. Минем бабам да Бөек Ватан сугышында катнашкан. Ул, 18 яшь тулгач, 1942 нче елның 7 нче октябрендә Кызыл Армия сафларына баса, 353 нче полкта укчы була. 1942 нче елның декабреннән 1945 нче елның сентябренә кадәр 324 номерлы гвардия миномёт полкы составында сугышларда катнаша. Бөек Ватан сугышының 2 нче дәрәҗәле ордены, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында "Германияне җиңгән өчен" медале һәм башка медальләр белән бүләкләнгән. Мин бабам белән чын күңелдән горурланам. Мин сезгә үзегезнең классыгызның Хәтер китабын төзергә тәкъдим итәм. Укучылар, сезнең төп бурычыгыз: булачак хәтер китабына Бөек Ватан сугышында сезнең гаиләдән катнашкан бабагызның, дәү бабагызның, туганыгызның исемен, фамилиясен өстәлегездә яткан кәгазьләргә язарга кирәк. Башладык, балалар! (вакыт бирелә). Һәр команда Ватан сугышында катнашкан дәү бабасы, туганын яза һәм «Минем бабам – миллионнарның берсе» дип язылган стенд астына (*сугышта үлгән дәү бабаларының тулы исем-фамилиясен язып*) элә. Күрәсезме, укучылар күпме исем, фамилия язылган. Аларның һәрберсе безгә бик кадерле. һәрбер исем артында тулы бер язмыш бит. Укучылар, бу сугышчан биремне дә бик яхшы эшләдегез, һәрбер командага берәр балл бирелә һәм киләсе рәсемне ачабыз. Анда «ел» дип язылган.

- Укучылар, без сезнең белән алдыбызга куелган сугышчан бурычыбызны үтәдек. Әйдәгез кычкырып укыйк: «Бөек Җиңүгә – 75 ел!»

- Укучылар, безнең бу очрашуыбызның темасы ничек әле?

- «Онытырга хакыбыз юк,
онытырга кушмый Мусалар!»

- Ә нәрсәне онытырга ярамый?

- Әйе, тынычлык өчен гомерләрен биргәннәрне онытырга ярамый. Чыннан да, сугыш ул – кайгы, хәсрәт, күз яшьләре, газап, бәхетсезлек. Әйе, без тынычлыкның кадерен белергә тиеш.

- Ә нәрсә соң ул тынычлык?

- Әйе, **тынычлык ул – бәхет, шатлык, елмаю, кояш, зәңгәр күк йөзе.** Укучылар, тынычлык символын нинди кош сүрәтли? (*Күгәрчен)* Мин дә сезне очрашуыбыз ахырында шушы күгәрченнәрне җир шарына беркетергә чакырам. Сезгә бу тема күңелегезгә якын булса, кызыксындырса – ак күгәрченнәрне утыртыгыз. Әгәр дә бу тема сезне бөтенләй кызыксындырмаса – зәңгәр

күгәрченнәрне утыртыгыз. Карагыз әле, безнең җир шарында ак күгәрченнәр генә. Рәхмәт, балалар!

Укучылар, сезнең күкләрегез һәрчак аяз, күңелләрегез тыныч булсын. Бүгенге сөйләшүебез эзсез калмас, дип ышанып калам.

Әңгәмәбезне Әхсән Баянның бер матур шигыре белән тәмамлыйм:

**Сынадылар еллар, сынатмадык,**
**Әҗәлләр һәм туплар яуса да,**
**Югалтулар искә төшкән чакта,**
**Йөрәкләргә кабат кан сава.**
**Онытмагыз:**
**Берни безгә җиңел бирелмәде,**
**Һичбер җиңү бушка килмәде.**
**Котычкыч авыр еллар бәясенә**
**Яулап алдык без бу көннәрне!**

Балалар, бүгенге очрашуыбыз тәмам. Сезгә матур җавапларыгыз, актив катнашуыгыз өчен бик зур рәхмәт! Саубуллашу.

## Дәрестән тыш чараның проекты
## Тема*:* Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк

*Сәфәрова Алсу Габделхак кызы,*
*Казан шәһәре Яңа Савин районының "Инглиз телен тирәнтен өйрәнелә торган 165 нче урта гомуми белем мәктәбе" муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Предмет:** Туган (татар) тел, әдәбият
**Сыйныф:** 6 нчы (татар төркеме)
**Дәрестән тыш чараның формасы:** иҗади остаханә
**Дәрестән тыш чараның юнәлеше:** гомуми интеллектуаль
**Дәрестән тыш чарага максатлар:**
***Эшчәнлек буенча:*** эш гамәлләренә күнекмәләрне камилләштерү: ныгыту, эзләнү, текст, портретлар белән эш.
***Эчтәлек буенча*****:** ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан халкыбызның бөек шәхесләре М.Җәлил, Р.Яхин, М.Шәймиев турында белемнәрне ныгыту, формалаштыру.
**Планлаштырылган нәтиҗәләр***:*
***Шәхескә кагылышлы***: күренекле шәхесләрнең тормыш юлын белү, алар белән горурлану, дәрестән тыш чарада өйрәнгән теманы, үзләштергән белемне гамәлдә куллана белү.

***Метапредмет:***

***Танып белү УУГ:*** кирәкле мәгълүматны таба белү; үз фикереңне дәлилли алу, мөстәкыйльлек булдыру, максат кую, текстны аңлап уку, сөйләм күнекмәләрен булдыру, эшне җаваплы аңлап башкару.

***Регулятив УУГ:*** үз эшчәнлегеңне контрольгә алу,үзеңнең һәм башкаларның фикерен дөрес бәяләү, эшләнгән эшнең сыйфатын, дәрәҗәсен билгеләү.

***Коммуникатив УУГ*****:** сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү, коммуникатив максатлардан чыгып фикерне дөрес һәм урынлы куллану, төркемдә, парларда эшли белү, әңгәмәләрдә катнашу, мәгълүматны туплау өчен, кумәк эш башкару.

***Шәхси УУГ:*** тыңлый һәм сораулар бирә белү, үз карашыңны дөрес әйтү һәм дәлилләү, иҗади хезмәттәшлеккә омтылу.

**Предметара бәйләнеш**: татар әдәбияты, татар теле, тарих, сәнгать.

**Эшне оештыру:** индивидуаль, парларда, төркемдә.

**Метод һәм алымнар:** эзләнү, укытучы сөйләве, укучыларның сорауга җавап бирүләре, текст белән эш, бәйләнешле сөйләм үстерү, дифференциаль якын килү һ.б.

## 1. Дәрестән тыш чараның барышы

**Укытучы**. Хәерле иртә, укучылар! Кәефләрегез ничек? Минем дә әйбәт. Тактага игътибар итегез әле.

*Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк.*

Сез бу татар халык мәкален ничек аңлыйсыз?

**Укучылар.** Һәр кеше үткәнен, тарихын белергә тиеш.

**Укытучы.** Ни өчен шулай дип уйлыйсыз?

**Укучы.**Үз халкыңның тарихын белеп, ялгышлыкларны, уңышларны күреп, киләчәк төзергә була.

**Укытучы**. Мин килешәм, рәхмәт. Укучылар, искә төшерик әле, быел нинди вакыйгаларны билгеләп үтәбез?

**Укучылар.** Бөек Җиңүнең 75 еллыгы, ТАССР оешуга 100 ел.

**Укытучы.** Истә калдыргансыз икән, бик яхшы. Чыннан да, ТАССРның оешуы – татар халкы өчен зур вакыйга ул. 100 ел эчендә безнең илебез үскәнме? Нинди мисаллар китерә аласыз?

**Укучылар.** Халкы арткан, шәһәрләр, заводлар үсеп чыккан, Татарстан Республикасы барлыкка килгән һ.б.

**Укытучы.** Яхшы, бу вакыйгаларны кемнәр булдыра соң?

**Укучы.** Кешеләр, шәхесләр.

**Укытучы.** Сез хаклы. 100 еллык тарихыбызны бөек шәхесләребез барлыкка китергән. Без бүген аларның өчесенә тукталырбыз.Тактага игътибар итегез: алар кемнәр?

**Укучы**. М. Шәймиев, М.Җәлил...

**Укытучы.** Әйе, укучылар, Бөек Ватан сугышында катнашкан ватанпәрвәр шагыйребез М.Җәлил белән Татарсан Республикасының беренче президенты Шәймиевне кичәге дәрестән истә калдыргансыз, дип уйлыйм. Ә өченчесе кем?

**Укучылар.**?

**Укытучы.** Мин сезгә ярдәм итәм. (Татарстан Республикасының гимны тыңлана)

**Укытучы**. Нәрсә яңгырады?

**Укучылар.** Татарстан Республикасының гимны.

**Укытучы**. Бу шәхеснең гимн белән бәйлелеге нидә? Ул кем?

**Укучылар.** Ул гимнның көен язган. Бу - Рөстәм Яхин.

**Уктучы.** Димәк, без бүген ТАССР, Татарсан Республикасы тарихына зур өлеш керткән шәхесләребез М.Шәймиев, М.Җәлил, Р.Яхин турында сөйләшербез.Үз алдыбызга нинди максат куярбыз?

**Укучы.** Өч шәхес турында, аларның ТАССР тарихына керткән өлешен белергә.

**Укытучы.** Дөрес. Һәр төркемгә бер шәхес, аның биографиясенең бер өлеше. Җөмләләр төрле тәртиптә бирелгәннәр. Сезгә саннарга, даталарга игътибар итеп, аларның хронологиясен булдырырга, җөмләләрнең урыннарын табарга кирәк. 1 нче төркем – М. Җәлил, 2 нче төркем – Р. Яхин, 3 нче төркем – М. Шәймиев.

*1 нче төркем*

Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елда Ырынбур өлкәсе Мостафа авылында туа. Ул кече яшьтән үк зирәк һәм хыялга бай бала була. Күп укый, һәр нәрсәне белергә тырыша, оста итеп мандолинада уйнарга өйрәнә, рәсем ясарга ярата.

Муса 10-11 яшьләрендә шигырьләр дә язып карый. Ләкин алар югала. Матбугатта иң беренче булып унөч яшендә язылган «Бәхет» шигыре (1919) басыла.

*2 нче төркем*

Рөстәм Яхин 1921 елның 16 августында Казанда хезмәткәр гаиләсендә туган. Рөстәм Яхин кечкенәдән үк музыка белән кызыксына башлый.

3 яшендә пианинода үзлегеннән халык көйләрен уйный башлый. П.И.Чайковский исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбендә белем ала. 13 яшендә музыка мәктәбенә укырга керә һәм 7 еллык мәктәпне 3 елда тәмамлый. Ул бик сәләтле, тырыш бала була.

*3 нче төркем*

Минтимер Шәрип улы Шәймиев 1937 нче елның 20 нче гыйнварында хәзерге Актаныш районы Әнәк авылында туа. Минтимер Шәймиевның балачагы, яшьлеге шунда үтә.

М. Ш. Шәймиевнең бабасы — Шәймөхәммәт урта хәлле, таза тормышлы игенче булган.

1954 елда М. Ш. Шәймиев Пучыда урта мәктәпне тәмамлый һәм Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга керә.

**Укытучы.** Тикшерәбез, төркемнәрдә берешәр җөмлә укыйбыз, тактага карыйбыз. Игътибар итеп барабыз: шәхесләребез турында сөйләгәндә, безгә саннар кирәкме?

**Укучы.** Әйе. Саннар безгә биографияне сөйләргә, вакыйгаларны хронологик рәвештә урнаштырырга ярдәм итә.

**Укытучы.** Сез ТАССР тарихына зур өлеш керткән шәхесләребезнең тормыш юлларының бер өлешен генә белдегез. Татар халкының әлеге бөек шәхесләре белән якынрак танышу, алар турында күбрәк белү өчен, парларда бер эш башкарырбыз. Сезнең алдыгызда ноутбуклар, аларның эш өстәлендә “ТАССРның 100 еллыгына өч исем” дигән папка бар. Сезгә үзегезнең шәхесегезгә кагылышлы материалны гына тупларга кирәк була. (Әлеге папкада фото, аудио, видео материаллар, язма документлар бирелгән, шулардан үзләренә кирәкләрен генә туплыйлар. М.Шәймиев, М.Җәлил, Р.Яхинга бәйле яңа папкалар булдыралар).

**Укытучы.** Нинди материаллар таптыгыз, тупладыгыз (Һәр төркем үз шәхесе турында сөйли, чыгыш ясый).

**Укытучы.** Рәхмәт, укучылар, бүген нәрсәләр белдегез? Нәрсәләр ошады?

**Укытучы.** Инде әлеге шәхесләребез турында белерсез, тарихыбызны онытмассыз, киләчәктә үзегез дә олы шәхесләр булырсыз дип ышанам. Сау булыгыз!

## Эчтәлек

Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру (гимназия эше тәҗрибәсеннән) .....3

Хөснетдинова Э.Р., Казан шәһәре Г.Тукай исемендәге беренче татар гимназиясенең туган тел һәм әдәбияты укытучысы

«Татар орнаменты үрнәкләре. Сөлге» ....8

Макарова И.А., Корманова А.Ш., Казан шәһәре Совет районы «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 144 нче урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең югары квалификацион категорияле һәм беренче квалификацион категорияле туган тел укытучылары

"Халкыбызның күңел җәүһәрләре" дәрестән тыш эшчәнлек программасының 21 нче дәресе ....12

Фәхриева Л.Г., Казан шәһәре Совет районы "108 нче төп гомуми белем мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Татар халык уен җыры "Кәрия-Зәкәрия" ....18

Бикмөхәмәтова Л.З., Казан шәһәре Идел буе районы «6 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Совет районы мәгариф бүлегенең милли мәсьәләләр буенча методисты

"Бәллүр каләм" җыены дәрестән тыш эшчәнлек программасының 14 нче дәресе ....22

Җәләлиева Л.Р., Макарова И.А., Казан шәһәре Совет районының «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 144 нче урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең югары квалификация категорияле туган тел укытучылары

Дәрестән тыш чара "Һөнәрләр дөньясына кереш" программасы буенча (10 нчы шөгыль) ....37

Нургалиева Г.М., Казан шәһәре Мәскәү районы 94 нче гимназиянең югары квалификацион категорияле туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы

Тел күрке – сүз ....40

Шәгәрәева А.И., Казан шәһәре Яңа Савин районы 13 нче татар гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

"Әйтем — сүзнең бизәге, мәкаль — сүзнең җиләге" ....44

Сөнгатуллина Р.Ф., Казан шәһәре Совет районы 141нче гимназиянең туган татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Кояшлы ил – безнең ил (ТАССР оешуга – 100 ел тулу уңаена дәрестән тыш чара)....50

Әхтәмова Г.М., Казан шәһәре Совет районы 175 нче гомуми урта белем мәктәбенең югары категорияле туган тел һәм әдәбият укытучысы

Муса Җәлил-балаларның якын дусты ....54

Галәветдинова Л.Г., Ибраһимова Э.С., Казан шәһәре Авиатөзелеш районы 62 нче урта гомуми белем мәктәбенең туган (татар) тел укытучылары

Дәрестән тыш эшнең проекты. «Сертотмас үрдәк аппликациясе” ................................59
Галкина Т.Г., Казан шәһәре Яңа Савин районы 13 нче татар гимназиясенең башлангыч сыйныф укытучысы
Дәрестән тыш эшнең проекты. Татарстан минем туган ягым .......................................61
Ибраһимова Э.М., Казан шәһәре Яңа Савин районы 13 нче татар гимназиясенең башлангыч сыйныф укытучысы
Шәвәли бездә кунакта (5 нче сыйныфта дәрестән тыш чара) ......................................64
Садриева Х.Г., Казан шәһәре Яңа Савин районы 13 нче татар гимназиясенең туган тел (татар теле) һәм әдәбияты укытучысы
Куәтле бит ул безнең ил! ..........................................................................................67
Гыйләҗева Э.З. Казан шәһәре Мәскәү районы КФУ каршындагы 2 нче татар гимназиясенең беренче квалификацияле математика һәм информатика укытучысы
Онытырга хакыбыз юк, Онытырга кушмый Мусалар! ..................................................73
Фәсахова М.Р., Казан шәһәре Совет районы 15 нче урта гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Дәрестән тыш чараның проекты. “Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк”........................79
Сәфәрова А.Г., Казан шәһәре Яңа Савин районының "Инглиз телен тирәнтен өйрәнелә торган 165 нче урта гомуми белем мәктәбе” муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Эчтәлек .......................................................................................................................83

**Федераль дәүләт белем стандартлары кысаларында дәрестән тыш эшчәнлек шөгыльләрен модельләштерү.**
**Методик җыентык**

Тираж 200 экз.
Отпечатано в информационно-методическом отделе
Управления образования ИКМО г.Казани
420111, г.Казань, ул.Б.Красная, 1, тел.292-26-12